www.madanizhomga.ru

Мәдәни җомга

1995 елның июленнән башлап чыга

Татарстанда язылу индексы – П2355.

№ 48 (1464) 8 декабрь 2023 ел

БЕЗ СОЦИАЛЬ ЧЕЛТӘРЛӘРДӘ:

madani_zhomga madanizhomga

madani_zhomga



12-13

Күренекле рәссам Фәйзрахман Әминевнең улы Фәйзулла гомер буе Петербург каласында яшәсә дә, татар теленә һәм милли сәнгатькә мәхәббәтен җуймаган, ул һаман да безнең лаек вәкилебез.

14-15

Мәскәү каласын дошманга бирмичә саклап калуда каһарманлык кылган, әмма Вязьма казанына кертеп юкка чыгарылган генерал Ефремов язмышы бик кызганыч.

16-17

Бөек Ватан сугышына кадәр советлар илендә биш кенә хәрби икешәр мәртәбә Советлар Союзы Герое исеменә лаек булган, әмма шундый каһарманнарның да берсе атып үтерелгән.

Илгә кайталмаган каһарманның Рухы шат булсын, ярабби!..

БЕР ҖӨМЛӘ БЕЛӘН...

- Рөстәм Миңнеханов 2024 елга Татарстан бюджеты турында законны имзалады.
- Татарстан Республикасы «Иң күп укучы төбәк-2023» Бөтенроссия конкурсында җиңүче дип танылды.
- Халык хуҗалыгы казанышлары күргәзмәсендә (ВДНХ) «Россия» халыкара күргәзмә-форумында Татарстан Республикасы көннәре узды.
- Татарстан Рәисе Р.Миңнеханов Мәскәүдә И.Сеченов исемендәге медицина университетында булды, анда укучы Татарстан студентлары белән очрашты.
- Дәүләт Советында КПРФ фракциясе инициативасы буенча «Тарихи мирасны, милли мәдәниятләрне һәм традицияләрне саклау һәм үстерү нигезе буларак эчке туризм» дигән түгәрәк өстәл утырышы узды.
- Азәрбайҗанда Татар мәгарифе көннәрендә Каюм Насыйри исемендәге белем бирү үзәге ачылды.
- Ижевскиның Халыклар Дуслыгы йортында «Татарча QR-Код: Татар ханнары тамгалары» күргәзмәсе ачылды.
- Апасның яңа урамына Татарстанның халык шагыйре Шәүкәт Галиев исеме бирелде.
- «Киләчәк уеннары» символы булган капсула «Прогресс МС-25» йөк корабле бортында космоска җибәрелде.
- Мурманск шәһәрендә “Якташ” татар җәмгыяте белән берлектә балалар-яшүсмерләр китапханәсе беренче тапкыр Тукай укулары оештырды.
- 2023 елның ун аенда Казанда 1,1 меңнән артык юл-транспорт һәлакәте булган.

БЕЛЕП ТОРЫГЫЗ

8 декабрь – тарихчы, тел-әдәбият белгече һәм җәмәгать-сәясәт эшлеклесе Габделбари Габдулла улы Баттал-Таймас (Сәетбатталов)ның тууына 140 ел (1883-1969).

9 декабрь – педагог, тел галиме, профессор, ТАССРның атказанган фән эшлеклесе, Хезмәт Батыры Мөхетдин Хафизетдин улы Корбангалиевнең тууына 150 ел (1873-1941).

10 декабрь – язучы, әдәбият галиме, җәмәгать эшлеклесе, ТАССРның атказанган мәдәният хезмәткәре, Татарстанның Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләге лауреаты Ринат Сафа улы Мөхәммәдиевкә 75 яшь (1948).

14 декабрь – скрипкачы, дирижёр, педагог, Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе Рөстәм Ибраһим улы Үтәйгә 80 яшь (1943).

СЫНАМЫШЛАР

9 декабрьдә кар күп булса, 6 майда чирәм үскән була ● 12 декабрьдә кар яуса, 19 декабрьгә кадәр буран котырачак; аяз булса, ай буена кояш куандырачак ● Ай киртәләнсә, тиздән буран булыр ● Болытлар түбәннән килсә, каты суыкны көт.

КОЯШ СӘГАТЕ

Бүген кояш **8 сәгать 00 минутта** чыкты, һәм ул **15 сәгать 13 минутта** офык артына күмеләчәк. Көн озынлыгы – **7 сәгать 13 минут.** Алдагы җиде көн дәвамында тәүлекнең якты вакыты **10 минутка** кыскарачак һәм киләсе җомгада, ягъни **15 декабрьдә 7 сәгать 03 минут** тәшкил итәчәк.

СӘЛАМӘТЛЕК КӨН ДӘ КИРӘК

Декабрьнең магнитлы авыр көннәрендә хезмәттәшләрегез, якыннарыгыз сәламәтлегенә һәм, әлбәттә, үз-үзегезгә аеруча игътибарлы булыгыз. **Андый көнне исегезгә төшерәбез: 10 декабрь.**

* * *

Гадәттә, айның соңгы чирегеннән яңа айга кадәр **(5-13 декабрь)** организм киңәюгә бара. Мондый көннәрдә юан эчәклекне чистартуга бәйле процедуралар үткәрү файдалы.

ҺИҖРИ БУЕНЧА 1445 ЕЛ

Бүген җөмәдел әүвәл аеның 25 нче көне

ҖАН АВАЗЫ

Фәүзия БӘЙРӘМОВА

Атласи һәм Туйкиннар Казанга кайтырмы?..

Көз көне Казанның милли тормышында искә алырлык вакыйга булып узды – Татар китабы йортында бертуган Туйкиннар атналыгы уздырылды. 1938 елның 15 февралендә Һади Атласи белән бергә атып үтерелгән абыйлы-энеле Кәбир һәм Фазыл Туйкиннарны, золым корбаннарын искә алу иде ул...

Бөгелмә-Шөгер төбәгендә туып-үскән бу туганнар гомер буе балалар укыткан, дәреслекләр, фәнни һәм әдәби хезмәтләр язган, халык авыз иҗатын җыйган, аларны матбугатта бастырган. Ләкин кайбер хезмәтләрен, бик теләсәләр дә, Казанда бастырып чыгара алмаганнар. Шулай ук аларның Казанда яшәү һәм эшләү хыялы да тормышка ашмый. 1937 елны бертуган Туйкиннарны Казанга тоткын хәлендә, богаулап китерәләр һәм халык дошманы, дип атып үтерәләр. «Укытучылар эше – Атласовщина» дип аталган бу җинаять эше буенча Бөгелмә-Әлмәт төбәгеннән 107 татар кулга алына, алар арасында күпчелеге укытучылар була, аннан муллалар, хезмәткәрләр. 1937 елның октябрь аенда берьюлы 24 кешегә суд була, 9 кеше атып үтерүгә хөкем ителә. Шул тугызның икесе – абыйлы-энеле Туйкиннар...

Моңа кадәр Туйкиннарны алар эшләп киткән Бөгелмәдә һәм нәсел дәвамчылары яшәгән Әлмәт шәһәрендә генә искә алалар иде. Ниһаять, алар рухы каршында Казанда да баш иделәр... Мәдәният министрлыгы, музейлар берлеге, Татар китабы йорты уздырган мондый атналык Туйкиннардан башланды. Аңа музейлар күргәзмә алып килгән иде. Анда Кәбир һәм Фазыл Туйкиннарның китаплары, тарихи фотолар, документлар, бертуганнарның шәхси әйберләре куелды. Борынгы Туйкә нәселенең туган төбәге булган Зәй-Каратай (Лениногорск районы) авылы музееннан да махсус күргәзмә килде.

Туйкиннарга багышланган бу чаралар барышында репрессия корбаннары мемориалында алар рухына Коръән укылды, исемнәрен әйтеп, дога кылынды, чәчәкләр салынды. Биредәге ак мәрмәр ташларга шул елларда атып үтерелгән меңләгән кешенең исеме уеп язылган. Алар арасында 1938 елның 15 февралендә атып үтерелгән Һади Атласи, Кәбир Туйкин, Фазыл Туйкин, Гани Алтынбаев, Касыйм Исхаков, Сабир Уразманов, Барый Фәттахов, Зәкәрия Фәттахов, Рәшит Яруллин исемнәре дә бар. Барый Фәттахов белән Зәкәрия – аталы-уллы, Барый хәзрәткә 63 яшь, улына 28 була. Һади Атласи белән Рәшит хәзрәт – баҗайлар, Фәттаховлар белән хатыннары ягыннан туганнар. Рәшит Яруллин – киләчәктә дөньякүләм танылу алачак тарихчы Әхмәт Тимернең әтисе. Лашман мулласы Касыйм хәзрәт Исхаков – Гаяз Исхакыйның туганы. Күрәсез, иң затлы татарларны, милли элитаны сайлап алып юкка чыгарганнар... Мемориалга Казан, Әлмәт, Уфа, Бөгелмә, Лениногорски районнарыннан Туйкиннарның нәсел дәвамчылары килгән иде. Алар бабаларының исеме уелган ташны озак вакыт буе бармаклары белән капшап торды, гүя аларның җаннарын җылытырга теләде...

Аннары Татар китабы йортында «Туйкиннарның иҗади һәм педагогик мирасы» дигән темага түгәрәк өстәл утырышы узды. Галимә, филология фәннәре кандидаты Эльмера Ханнанова-Галимҗанова әле 2004 елда ук «Фазыл Туйкинның иҗат мирасы» дигән темага кандидатлык диссертациясе яклаган булган. Утырышта да ул төп докладны ясады, Фазыл Туйкин иҗаты буенча күп мәгълүмат бирде. Эльмера ханым иске татар теле буенча белгеч, ул Фазыл һәм Кәбир Туйкиннарның хезмәтләрен гарәп әлифбасыннан кириллга күчергән икән.

Шагыйрә Эльмира Шәрифуллина исә 1972 елда ук Фазыл Туйкин иҗаты буенча Казан дәүләт университетында диплом эше язган, фәнни җитәкчесе Мөхәммәт Мәһдиев булган. Ул шул вакытта ук Уфага барып, Ф.Туйкинның хатыны, балалары белән очрашкан. Эльмира ханым Ф.Туйкинның 1912 елда басылып чыккан «Җырлар әхтәрисе» дип аталган китабын, гарәп хәрефләреннән кириллицага күчереп, 2017 елда яңадан бастырып чыгарган, ул чарада катнашучыларга да таратылды.

Бөгелмәдән тарих фәннәре кандидаты, Һ.Атласи исемендәге иҗтимагый фонд җитәкчесе Алсу Мөхәммәтдинова үзенең чыгышында бер үк көндә атып үтерелгән Һади Атласи белән бертуган Туйкиннарның Бөгелмә төбәгендә милли мәгарифкә нигез салучылар булуын ачып салды. Аларның бу эшчәнлеге совет властеның беренче елларына туры килә. Мәгърифәтче-мөгаллимнәр биредә татар мәктәпләре, балалар йортлары ачалар, үзләре үк шунда укыталар, яңа чор өчен яңа дәреслекләр язалар. Аларга каршы ачылган җинаять эше дә «Укытучылар эше» дип атала, 1936-1938 елларда шул төбәктә кулга алынган 107 татарның 54 е укытучы була. Күреп торасыз, хакимият элек тә, хәзер дә иң беренче чиратта милли мәктәпләрне, мөгаллимнәрне юк иткән, Алсу ханым бу хәлләр турында җаны әрнеп сөйли...

Бөгелмә шәһәрендә 1994 елдан бирле Һади Атласи фонды эшләп килә, биредә милли рухны заманында Атласи һәм Туйкиннар тотып торган кебек, бүген дә бу урыс шәһәрендә татарлыкны шушы фонд, аның тирәсенә берләшкән милләтпәрвәрләр саклый. Биредә һәр елны февраль аенда Атласига һәм аның белән бергә атып үтерелгән татарларга багышлап, Хәтер кичәсе уздырыла. Әле дә ярый аларны искә алырга Бөгелмә бар!

Мин исә чыгышымны «Һади Атласи һәм бертуган Туйкиннар: уртак хезмәт һәм уртак язмыш» дип атадым. Әйе, аларның милләткә хезмәтләре дә, фаҗигале язмышлары да уртак булган. Һади Атласи да, бертуган Туйкиннар да – мәктәп-мәдрәсәләр тоткан, дәреслекләр язган мөгаллимнәр. Алар үзләре дә мәдрәсә белеме алган дин әһелләре. Атласи белән Туйкиннарның тагын бер уртаклыгы – алар тарихчылар. Һади Атласи әле инкыйлабка кадәр үк үзенең данлыклы «Себер тарихы», «Сөембикә», «Казан ханлыгы» китапларын язып бастырган, аларны милләт бүген дә сокланып файдалана. Ә менә Кәбир һәм Фазыл Туйкәнең 1919 елда Ырынбурда басылып чыккан «Төрек тарихы» китабын бик азлар гына белә. Энциклопедик дәрәҗәдәге бу хезмәт өч томнан торырга тиеш булган, әмма шушысы гына чыгып калган, башкалары юкка чыккан. Бу китап дәреслек рәвешендә язылган, укырга җиңел, мәгълүматка бик бай. «Бертуган Туйкиннар» китабына кереш сүз язган галим Миркасыйм Госманов та Туйкиннарның бу хезмәтен югары бәяли, «Бертуган Туйкиннарның «Төрек тарихы» исемле китабы эчтәлегенең киңлеге, тәкъдим ителгән материалларның байлыгы җәһәтеннән шул чорда татарча басылып чыккан тарихи хезмәтләр арасында иң күренекле урыннарның берсен биләп тора», ди ул. М.Госманов аларны тарихчы буларак «Шиһабетдин Мәрҗани, Риза Фәхреддин һәм Һади Атласилар салган сукмаклардан барган» дип яза.

«Төрек тарихы» хезмәте белән «Бертуган Туйкиннар» китабында танышырга була, аны галимә Эльмера Ханнанова-Галимҗанова гарәп хәрефләреннән кириллга күчереп, тулысынча бастырып чыгарган. Бу китапны русчага да тәрҗемә итеп, ике телдә яңадан бастырып чыгаруларын көтәсе кала...

Ни аяныч, Атласи һәм Туйкиннарның төрмә тарихлары да уртак. Атласины милләт өчен төрмәгә беренче тапкыр 1909 елда утырталар, шушы ук елны имам-мөгаллим Кәбир Туйкин да яңача укыткан өчен төрмәдә утырып чыга.

(Дәвамы 4 нче биттә).

Татарның кыйбласы – Казан

27-28 ноябрь көннәрендә Казанда татар эшкуарларының XVI халыкара җыены уздырылды. Бөтендөнья татар конгрессы башкарма комитеты әлеге чараны быел да Татарстан Республикасы Сәүдә-сәнәгать палатасы белән берлектә оештырды.

Беренче көнне эшлекле хезмәттәшләр биш секциягә бүленеп максатлар ачыклады. Кичке якта БТК башкарма комитетының Милли Шура утырышы булды. Анда еллык эшкә хисап ясалды, конгресска яңа әгъзалар кабул ителде. 2024 ел конгресс тарафыннан «Шәхесләр елы» дип билгеләнде.

28 ноябрь көнне эшмәкәрләр җыенның пленар утырышында очрашты. Чарада илебезнең 44 төбәгеннән, 14 чит илдән 350 гә якын эшкуар катнашты. Җыен барышында Кыргызстаннан, Таулы Алтай Республикасыннан, Самара, Әстерхан, Курган өлкәләреннән, Омск, Төмән шәһәрләреннән килгән эшкуарлар үз тәҗрибәсе белән уртаклашты. Янгын афәтенә тарыган Курган өлкәсенең Эчкен-Йолдыз авылын торгызуга багышланган ярдәм чараларына аеруча зур игътибар бирелде. Бу табигый да. Бүгенгә кадәр Эчкендә 83 яңа йорт салынган, тәгаен алганда, «Татнефть» берләшмәсе 18 йорт корып куйган. «Татар-мөселман дөньясының бердәмлеген күрсәтүче, ихласлыгыбызны сынаучы зур гамәл бу», – дип билгеләрде әлеге уңайдан Татарстан хөкүмәте вице-премьеры, конгрессның Милли Шура рәисе Васил Шәйхразыев.

Җыен ахырында Татарстан Республикасы Рәисе Рөстәм Миңнеханов: «Һәрберегезнең бирегә чыгып сөйләрлек зур эшләре бар. Без сезнең белән горурланабыз. Татарның кыйбласы – Казан, дип сезгә борынгы тарихыбызны аңлатырга, ирешкән казанышларыбызны күрсәтергә тырышабыз. Кайда гына яшәсәк тә, без бер-беребезгә бик кирәк», – дип җыен эшчәнлегенә зур бәя бирде. «Шактыебызга туган телебезне яхшылап өйрәнергә туры килмәде, татарча сөйләшергә кыенсындык. Хәзер заман башка. Телебезне өйрәнү өчен бик күп техник мөмкинлек бар. Яшь, үсә торган буын татар телен белергә тиеш», - дип республика башлыгы балаларда хезмәткә, телебезгә, динебезгә мәхәббәт тәрбияләргә чакырды, аеруча зур уңышларга ирешкән милләттәшләребезгә дәүләт бүләкләре тапшырды.

Рәшит МИНҺАҖ.

Гадел Кутуйны яд итү

Казан каласының Мөштәри урамында 1929-1942 елларда язучы һәм шагыйрь Гадел Кутуй яшәгән йортка куелган истәлек тактасы (33 нче йорт), әдипнең барельефы өстәлеп, яңартып ачылды. Барельефны иҗат итүче – сынчы-рәссам Рөстәм Габбасов.

Татарстан Язучылар берлеге рәисе Ркаил Зәйдулла, тантананы ачып, сүзне Татарстан Республикасы Дәүләт Советы рәисе урынбасары Марат Әхмәтовка бирде. Башкалабыз җәмәгатьчелеге алдында Казан шәһәре башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Гүзәл Сәгыйтова, шагыйрьләрдән Рәдиф Гаташ, Зиннур Мансуров, Рүзәл Мөхәммәтшин, Гадел Кутуйның оныклары Диана Гаделшина белән Тимур Кутуев чыгыш ясады.

Ахырда берлек рәисе Р.Зәйдулла, күп кенә илләрдә моның үрнәге бар, дип Польшада җирләнгән әдипнең җәсәден ватаныбызга кайтарып җирләү мәсьәләсен дә искә төшерде.

1 нче биттә – Гадел Кутуйның яңартылган барельефын ачу тантанасы.

Мөслимдә – Каз өмәсе

Татар халкы гомер иткән һәр төбәктәгечә, Мөслим районының Ык елгасы буендагы авылларында да каз үстерүне үтә яратканнар. Бу якта бүген дә кош-корт үрчетү киң таралган. Әйтик, быел гына да район фермерлары – 130 мең, ә халыкта 40 мең каз үстерелгән. Аларны үстерү генә түгел, аны эшкәртергә дә кирәк. «Каз өмәләре барлык авылларда да үткәрелә. Кемдер 100, икенчеләре – 150, 1000 не дә үстерергә мөмкин. Хәтта каз йолкый торган бригадалар барлыкка килде», – дип сөйли Мөслим районы башлыгы Альберт Хуҗин. Шуңа да беренче карлар төшү белән авылларда каз өмәләре гөрли башлый. Андый өмәләр Татарстанда гына түгел, Россиянең дә татарлар яши торган барлык авыл-бистәләрендә гөрләп узды.

Мөслимнең үзәгендә «Бәхет» дигән кечкенә бакча булдырылып, анда «Пар каз» дигән гаҗәеп күңелгә ятышлы сын да куелган. Аны скульптор Фазыл Шияпов үзенең сабый һәм үсмер чакларын күз алдына китереп ясавын әйтә. «Композициядә халык рухын күрсәтергә тырыштым. Бер-берәнә ихтирам, ир һәм хатын-кыз, бала... Кыскасы, тулы гармония! Каз образында – хатын-кыз, ул борынын иренең түшенә терәгән. Ә ирнең ни эшләргә кирәк, шуңа әзер торуы, булдыклыгы чагылган. Бер-берсенең кочагына сыенган казлар гаиләдәге мәхәббәт һәм тугрылыкны гәүдәләндерә».

«Каз өмәсе» Бөтенроссия фестиваленең узуы өченче ел рәттән Мөслим җирлегендә үтүе дә бик табигый. Аңа әзерлек февраль айларында ук башланган. Халык рәссамы Мөдәррис Миңһаҗев җитәкчелегендәге оста куллар кунаклар өчен казга багышланган серия эшләгән. Мөслимгә Россия шәһәрләреннән рәссамнар җыелган. «Без бирегә татарның йөзек кашы булган казга багышланган симпозиумны башлап җибәрдек. Рәссамнар казны, аның бәбкәләрен ярата. 40 ка якын рәссам аралашып, ләззәтләнеп эшләдек. Без һәр картинаның ничек туууын да хәтерлибез. Мондагы халык хезмәткә, сәнгатькә омтыла», – ди ул.

Спорт сараенда узган каз өмәсе күренешләре дә гүзәл. Балалар канат сыдырса, килен-җиңгәчиләр каз мамыгы йолкый. Шунда ук каз мамыгыннан мендәр тутыру, май канаты, бизәнү әйберләре ясау буенча осталык дәресләре бара. «70х70»ле мендәргә 10 баш казның мамыгы керә. Мамыкны махсус капчыкларга тутырып машиналарда юабыз, исе булмасын өчен таратып киптерәбез», – ди алар. Янда кул осталары да үз эшләрен тәкъдим итә. Чигү бизәкләре белән композиция тудыручы Хәния Гәрәеваның иҗаты бик камил. Ул март аенда узучы Нәүрүз чыршысына чигеп уенчыклар әзерләгән. Нәүрүз гүзәлләре – курчакларны да киендергән. Рәссамның кул эшләре арасында күз явын алырдай янчыклар, баш киемнәре, калфаклар да бар.

Ә каз маеның шифасы турында һәркем белә, Мөслимдә аңа балавыз һәм төрле шифалы үләннәр кушып майлар ясаганнар. Фестивальнең икенче өлеше «Кояшлы Ык» ял зонасында дәвам итте. Бирегә каз югарга бару йоласы, каз йолкучы кызларның җырлы-биюле уеннары тәкъдим ителде.

Район мәдәният йортында «Мөслим бизәкләре» проекты буенча «Тылсымлы энә» исемендәге чигү бәйгесенә йомгак ясалды. Чигүле мендәрләр, сөлгеләр – барысы да зур осталык белән эшләнгән. Без «Сөлгеләр» номинациясендә җиңүче булып танылган Саба районыныың Кызыл Мишә авылыннан килгән технология укытучысы Рәсимә Әхмәтова белән гаплашеп алабыз. Ул 50 еллап – балачагыннан чигү сәнгате белән шөгыльләнә. Рәсимә бәйгегә тамбурлы чигү (элмәкләп чигү) ысулы белән җитен тукымага пар казлар төшергән.

Гомумән, быел «Каз өмәсе» фестивалендә катнашырга 471 кеше теләк белдергән. Алар арасында, Татарстан районнары, Ханты-Мансы автономияле округы,

Новосибирск, Омск, Свердловск, Пенза, Оренбург, Киров өлкәләре, Башкортстан, Татарстан, Удмуртия республикаларында яшәүчеләр бар. Фестивальдә иң яшь катнашучы Мөслим районыннан Кадрия Хантимеровага 7 яшь булса, Удмуртия республикасыннан килгән Нурсинә Минҗәева 90 ны тутырган. Бәйге әүвәл 7 номинация буенча алып барылган, 33 җиңүче сайлап алынган. «Милләт дигәндә, вак мәсьәлә юк. Каз җырларыбызга кергән икән, ул – безнеке. Мамык шәл дә – безнеке. Татар атларын генетика буенча дәлилләдек. Сабан туйларында, бәйгеләрдә «Аударыш» хәрәкәте барлыкка килде. Үзебезнең татар балы да бар. Татар бренды аеруча яшь буынга милләтебез белән горурлану, милли үзаңны үстерү өчен дә кирәк», – ди Бөтендөнья татар конгрессының Башкарма комитет җитәкчесе Данис Шакиров. Фестивальдә барган бәйгедә призлы урыннарны алучыларны мәдәният йортында хөрмәтләнде. «Каз каурые һәм канатларыннан халык кәсепләре эшләнмәләре» номинациясе призеры Сиринә Шаһабиева ясаган май канатларына күпләрнең күзе төште. Ул Кукмара районы Зур Сәрдек авылы балалар бакчасында тәрбияче булып эшли. Алар аны балалар бакчасында «Хезмәт иткән халык дан-хөрмәткә лаек» дигән проект итеп эшләгәннәр. Шуның нигезендә балалар белән күп каз асраган гаиләләрдә булганнар, каурыйлар сыдырып, май канатлары ясарга өйрәнгәннәр.

Фестивальнең гран-прие исә Мөслим районының «Агролидер» кооперативы җитәкчесе Ирек Хәмәдишинга тәгаенләнгән иде. Кунаклар «Каз өмәсе»ндәге бер гамәлне аның каз суяу һәм эшкәртү цехы белән танышудан башлады. Узган ел бу кооперативта 11 мең каз үстерелсә, быел алар исәбе 13 мең 200 гә җиткән. Йомыркалар саны исә 340 мең. 270 мең бәбкә чыгарганнар. Күп өлешен Россия төбәкләренә сатканнар. Бирегә шулай ук каз ризыклары ярминкәсе, гадәттәгечә, мулдан әзерләнгән иде.

Мәйданда каз йолку, эчен алу, каз канаты ату кебек бәйгеләр үтте, каз эшкәртү буенча осталык дәресләре барды. Новосибирск шәһәреннән килгән Рузалия Мөхәммәтованың житез, уңган куллары каз йолку, аны эшкәртү бәйгеләрендә сокланырлык булып истә калды. Ул «Каздан пешерелгән татар халык ашлары» номинациясе җиңүчесе дә булды.

Сөембикә Кашапова.
Автор фотосы.

Мөхетдин Корбангалиевны искә алу

Казанда, Татар китабы йортында, күренекле галим, мәгърифәтче, татарча укыту буенча йөзләгән дәреслекләр, сүзлекләр, методик әсбаплар авторы, әле сугышка кадәр үк КДУда татар теле һәм әдәбияты кафедрасына нигез салган профессор Мөхетдин Корбангалиевның тууына 150 ел тулу уңаеннан чаралар булып узды. Башта аңа багышланган күргәзмә ачылды, анда М.Корбангалиев белән бәйле сирәк фотолар, ул язган китаплар куелган иде. Бу күргәзмә Милли музейдан махсус китертелгән һәм ул 19 декабрьгә кадәр дәвам итәчәк.

М.Корбангалиевка багышланган чараның икенче өлеше түгәрәк өстәл рәвешендә үтте, анда галимнең нәсел дәвамчылары, якташлары, галимнәр, татар зыялылары катнашты. Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты өлкән фәнни хезмәткәре Мөслимә Шәкурова М.Корбангалиевнең методика буенча фәнни хезмәтләренә анализ ясады. Аның иң яхшы методик дәреслекләре 1917-1941 елларда язылган. Галимә Корбангалиевны «чын мәгърифәтче Халык укытучысы», дип атады, аның 1917, 1920 елларда чыккан «Ана теле методикасы» дигән китабы буенча бүген дә укытырга мөмкин булуын әйтте.

КФУ профессоры, педагогика фәннәре докторы Фирас Харисов Россия уку йортларында татар теле укытыла башлауны өч чорга бүлеп аңлатты – Екатерина II заманы, революциядән соң һәм СССР җимерелгәнгә кадәр вакыт аралыгы һәм 1990 елдан алып 2017 елга кадәр, ягъни, мәктәпләрдә милли телләр тыелганга кадәр чор. Ул М.Корбангалиевны татар телен саклап калуда титаник хезмәт башкарган шәхес, дип атады. Ф.Харисов «Шәхесләребез» сериясендә аңа багышланган китап та чыгарылырга тиешлеген әйтте.

Мин чыгышымны М.Корбангалиевнең нәселенә багышладым, бигрәк тә аның репрессиягә дучар булган кызы Мөкәррәмә язмышы турында сөйләдем. Галимнең ата-бабалары алпавыт Тәфкилевләрнең крепостной крестьяннары булган. М.Корбангалиев яшәгән чорда татарларда ике тапкыр хәреф алышына, гарәп хәрефләре белән дәреслекләр яза башлаган галим аларны латин имлясына күчерергә тиеш була. Инде анысына ияләнеп беткәндә, латинны ашыгыч рәвештә кирилл хәрефләренә алыштыралар, тагын яңа дәреслекләр, уку китаплары, әлифбалар, сүзлекләр, методик кулланмалар кирәк була. Ул чорда аны юк итмәүнең бер сәбәбе – ул халык мәхәббәте. Әле 1921 елда ук аңа яшь Татарстан хөкүмәте «Хезмәт Батыры» дигән мактаулы исем бирә, 1925 елда аның 30 еллык хезмәтенә багышланган китап чыгара. 1926 елда Казан урамнарының берсенә аның исемен бирү турында карар чыгарыла, әмма ул үтәлмичә кала. Ә менә Мөкәррәмә исемле табибә кызын кулга алалар, 8 елга хөкем итәләр һәм сөргенгә сөрәләр, ирен атып үтерәләр, оныкларын да алып китеп, ябып куялар. Бу хәлләр 1938 елның гыйнварында була һәм ата кеше кызын, оныкларын коткарырга ташлана. Оныкларын ул палачлар тырнагыннан тартып ала ала, ә кызы Мөкәррәмә сөргендә ярты срогын тутыра, аннан гына авыру хәлдә Казанга кайтып егыла. Әмма ул кайтканда өч көн элек кенә әтисе үлгән була. 1941 елның 3 июнендә М.Корбангалиевнең йөрәге туктый... Халык дошманы, дип Мөкәррәмәгә Казанда калырга рөхсәт бирмиләр, ул балалары белән Минзәләгә китә, анда больницада рентгентолог булып эшли, үпкә чирле яралы сугышчыларны дәвалый. Сөргендә күргән газаплары сәбәпле, ул үзе дә рак белән авырый башлый һәм 1949 елда, 45 яшендә, бакыйлыкка күчә...

Мөхетдин Корбангалиевнең олы улы Салих, үз артыннан күзәтүләр сизгәч, эзәрлекләүләргә дучар булгач, Ленинградка күчеп китәргә мәҗбүр була. Югыйсә, ул да Казанда бик танылган шәхес була бит – Татарстан Җөмһүриятенең Сәламәтлек саклау комиссариаты (министрлыгы) җитәкчесе, атаклы табип, Казан дәүләт медицина институтының беренче ректоры... Хирург буларак, ул сугышның башыннан ахырына кадәр катнаша, сугыштан соң медицина буенча докторлык диссертациясе яклый. Казанда Салих Корбангалиев исемендәге урам бар, ә аның атасы Мөхетдин исемендәге урам юк.

Мөхетдин Корбангалиевнең икенче кызы Хәлимә – биология фәннәре докторы, КГУ профессоры, әтисенең архивын барлап, 2008 елда галимә Флера Сафиуллина белән аның турында китап чыгарган кеше. Мөхетдин Корбангалиевнең төпчек улы Рөстәм – сугыштан аяксыз кайта, химик, гомер буе югары уку йортында белем бирә. Бабаларының олуг юбилеенда Мөкәррәмәнең оныгы Регина Сәйфи һ.б. чыгыш ясады.

Фәүзия БӘЙРӘМОВА.

Атласи һәм Туйкиннар Казанга кайтырмы?..

(Ахыры. Башы 2 нче биттә).

Атласины икенче тапкыр 1921 елда, өченче тапкыр 1929 елда төрмәгә утырталар, 1931 елда Фазыл Туйкинны да хөкем итәләр. 1933 елда Соловкидан кайткан Атласи Бөгелмәдә эш таба алмый, 1934 елда гаиләсе белән Казанга күчә, 1936 елның июлендә, алтмыш яшенә бер ай кала, аны тагын кулга алалар һәм төрмәгә ябалар, бу юлы инде мәңге чыкмаска... 1937 елның гыйнварында Фазыл Туйкинны, февральдә абыйсы Кәбирне авылдан богаулап Казан төрмәсенә китереп ташлыйлар. Ел буе кыйнап, газаплап, 1937 елның 28 октябрендә хөкем карары чыгаралар, 1938 елның февралендә 9 татарны, бәйсез төрки-татар дәүләте төзәргә теләгәннәр, дигән яла белән атып үтерәләр. Казанда аларга суд булган, хөкем карары чыгырылган бинага истәлек тактасы куярга иде дә бит. Ул – элеккеге НКВД клубы иде, аны Менженский клубы, дип тә йөрттеләр, хәзер анда Пушкин исемендәге рус мәдәнияты үзәге. Ә рус итеге баскан җиргә татар михнәтчеләренең истәлеген кертүләре бик икеле. Ни кызганыч, Казанда Һади Атласи, Туйкиннар һәм алар белән бергә атып үтерелгән татар зыялылары истәлегенә бер ядкәр дә юк шул. Аларның хәтта каберләре дә юк... Истәлек тактасының үрнәге Бөгелмә шәһәрендә бар, аны Һади

Атласиның улы Угыз Атласов әтисе һәм бертуган Туйкиннар укыткан мәктәп диварына куйдырган иде. Хәзер шушы эшне Казанда эшләргә кирәк, монысы инде татар зыялылары эше…

Түгәрәк өстәл утырышында, галимнәрдән тыш, Туйкиннарның нәсел дәвамчылары, туганнары да чыгыш ясады. Әлмәттән төбәк тарихчысы, Габдрәхим Утыз Имәни, Р.Фәхреддиннның нәсел шәҗәрәләре турында уникаль китаплар язган Әлфия Ямаева, Казаннан Туйкиннар атналыгын уздыруда күп көч куйган нәсел дәвамчысы – Татарстан Мәдәният министрлыгының Җәмәгатьчелек шурасы әгъзасы Эльвира Рысаева, Бөгелмәдән Туйкиннарның нәсел дәвамчысы Әлфия Сафина, Әлмәттән «Тамырлар – Корни» тарихи һәм мәдәни мирасны саклау һәм үстерү фонды директоры, Туйкиннарның мирасын саклау өчен зур эшләр башкарган Марат Туйкин бабалары турында якты хатирәләр белән уртаклашты…

Бертуган Туйкиннарга багышланган атналык чараларына аларның күп санлы туганнары, оныклары, нәсел дәвамчылары килгән иде. Шушындый тарихи, бик мәгънәле, затлы атналыкны оештыру өчен Татар китабы йорты – Татар әдәбияты тарихы музее директоры Айдар Шәйхин да күп көч куйды. Мондый кадерле шәхесләребезне, бигрәк тә Атласи һәм Туйкиннар кебек золым корбаннарын Казан уртасында зурлап искә алсак, аларның һәйкәлләрен көтеп житкерү бәхетенә ирешсәк иде. иде! Быел Һ.Атласиның «Сөембикә», киләсе елга «Казан ханлыгы» китапларының басылып чыгуына 110 ел тула. Без Атласи һәм Туйкин истәлекләрен Казан уртасында күрә алырбызмы?..

● Россия халкы акча тотуны кыса башлаган. 2023 елның өченче кварталында сораштырылучыларның 41% кыйммәтле товар алуны туктаткан, 39% ял итү һәм күңел ачудан баш тарткан, 38% булган акчасын азык-төлек һәм иң кирәкле товарлар алу файдасына булгән. Шул ук вакытта азык-төлек алырга дигән акчаларын кысучылар саны да арта. Үзәк банк белдерүенчә, инфляциянең иң югары ноктасы өченче кварталда булган, язга кадәр чыдасак, төшәчәк икән.

● 2023 елның сентябрен дә кертеп исәпләгәндә, Россия халкы барлыгы 101,2 триллион сум кредит алган: 70,5 триллионы – бизнес алган займнар, 30,7 триллионы – халык җыйган кредит-ипотекалар. Бу ел башыннан кредитлар күләме 19% ка ишәйгән. Бер ел эчендә алынган ипотека күләме 32% ка, ә җан башына уртача керем 8,2% ка гына арткан. Бирелгән ипотеканың яртысы диярлек болай да 80% акчасын кредит түләүгә сарыф итүчеләрдә. Күрә торып бирәләр. Шул ук вакытта һәр икенче ипотеканың беренчел кертеме 20% тан да кимрәк булган.

Яратып киту

Ноябрь аенда язучы, тәрҗемәче, мөхәррир, сабакташыбыз Люция Гыйззәтуллинага (Нәҗмиева) 70 яшь тулды. Люция ханым гомер буе Татарстан китап нәшриятенең төрле бүлекләрендә эшләп, корректордан башлап, мөхәррир дәрәҗәсенә үсеп җитте. Тәрҗемәче булды. Аның тырышлыгы белән Лев Толстойның (аңа кадәр дә берничә мәртәбә тәрҗемә ителгән иде инде) «Хаҗи Морат»ын һәм башка авторларның китапларын татарчага тәрҗемә итеп, иң күп укыла торган дәрәҗәгә күтәрде.

Кулыма Гаяз Исхакыйның урысчага тәрҗемә ителгән китаплары килеп керде. Бер уйлаганда, алар миңа кирәк тә түгел кебек. Мин аларны үз телемдә, автор язганча да рәхәтләнеп укый алам. Телсезләребез, урысча гына укырга яратучыларыбыз, чыннан да, тәрҗемә ителгән китапларны сорый. Димәк, араларында Гаяз Исхакыйны ишетеп белүчеләр дә бар әле.

Исхакыйның тәрҗемәчесе 1933 елда туган Азалия Бадюгина. Кызыксынуым бермә-бер арта. Быел аңа 90 яшь тулды. Туган көне белән котлап, җылы бер сүз әйтеп куйсаң, шәп булыр иде дә соң. Әзлисе, җеп очын табасы бар бит әле. Люция Гыйззәтуллинага шылтыратам. Йомыш төшкәндә гел шулай. Сабакташым ул минем, аның татар китабына кагылышлы сорауларга беркайчан да җавап бирми калганы юк.

«Тәрҗемәче Азалия Бадюгинаны беләсеңме?» – дигән соравыма да ул рәхәтләнеп сөйләп китте. Люция 40 елга якын Татарстан китап нәшриятында аның белән бергә эшләде, аралашып яшәде. Бу юлы да ара-тирә хәл белешеп торган Азалия ханымга шылтыратып, аның өчен очрашасыбыз килгәнне бик итәгатьле итеп җиткерде. Ханым аптырап «очрашырбыз, күрешербез» дисә дә, вакытны гел күчерә торды. Яз җитсен, карлар китсен, җәй булсын, диде, җәйнең иң яраткан, иң күп эшли торган чагы икәнен дә әйтте. Соңгы хәбәре бик кätгый иде. Әлегә ул Мәхмүт Галәүнең «Болганчык еллар»ын тәрҗемә итә икән дә, аны бер дә туктатып торырга ярамый икән. Бер сүзсез килешәм, тәрҗемә эше һич җиңелдән түгел.

Соңгы елларда Люция Гыйззәтуллина белән ешрак аралаша башладык. Бервакыт: «Тәрҗемә әсәрләр автор язганнан да яхшырак булырга тиеш», – дигән иде ул. «Ничек алай булсын инде», – дип каршы төшәсем килсә дә, дәшмәдем. Икенче килүендә ул Лев Толстойның 1920-1930 елларда татарчага тәрҗемә ителгән китабын һәм үзе тәрҗемә иткән «Хаҗи Морат»ны алып килде. Мин дә чагыштыра-чагыштыра бер тында карап чыктым. Тәрҗемә белән тәрҗемә күк белән җир арасы, безнең Люциябез чын иҗади, әдәби тәрҗемәче икән шул. Аңа кадәр әле ул катлаулы, шул ук вакытта кызыклы да, бер әләккәнсең икән, ычкындырмый, як-ягыңа каратмый, җибәрми торган китап юлы үтә.

Китап юлы, китаплы юл. Люция бу юлга очраклы гына килеп керми. Бик яшьли китап укырга ярата ул. Такмак та чыгармый, шигырь дә язып азапланмый. Татар бүлегенә шундыйларны гына алалар кебек. Без Люцияләр белән университетта укырга кергәндә бер урынга 4-5 кеше иде. Әгерҗе кызлары Роза, Лилия, Люция бер төркемдә укыды, бишнең икесе читтән торып белем алды. 4 се төрле мәктәпләрдә татар теле, әдәп, әхлак укытты. Милләт өчен, милләт мәгарифе өчен армый-талмый эшләделәр. Алардан бер генә курска югары Гәүһәрия белән Вәсилә укыды. Тагын берничә Әгерҗе кызын беләм. Аларда уртак сыйфатлар бар. Алар алга чыкмый, тыныч-тыйнак кына үз укучысын милләтен, халкын, туган телен яратырга, якларга өйрәтә. Вәсилә Хәкимова дигәннәре әле дә Ижауга йөреп, төрле уку йортларында татар теле укыта. Халкыбыз арасында татар китаплары мәгърифәт нуры тарата. Эшнең берсеннән дә авырсынып тормыйлар. Татар теле, милләте генә югалмасын, бетмәсен. Кемнәрдер мәктәпкә бармаска, татар теле укытучысы булмаска йөргәндә, Люция Нәҗмиева туган авылына татар теле укытучысы булып кайтырга язылa. Ә диплом җитәкчесе Алмазия Нуриевна аспирантурага чакыра. Төрки телләрне чагыштырып диплом язганда аңарда эзләнүчән галимә күренә. Ләкин Аллаһ икенче язмыш язган. Адәм баласын Ул Үзе алып бара. Укыганда Люция тулай торакта урын җитмәгәннән фатирда тора. Ул Казанда билгеле, хөрмәтле Банат апа Аитова булып чыга. Укучылары, дуслары күп. Шулардан файдаланып, Люциягә эш урыны әзерли. Аңа кадәр әле чын татар баласы итеп үстерә. Дәресләр дә бирә, сабак та укыта. Татар шәхесләре язмышы белән таныштыра. Тырышлыгын күреп, Мәгариф министрлыгына барып, Люцияне Татарстан китап нәшриятына эшкә калдыруны сорый. Банат апасының ышандыру көче зур була, күрәсең. Люцияне берсүзсез корректор итеп эшкә алалар.

Казанда төрле редакцияләрдә эшкә калырга тырышып йөргән шагыйрь егетләребез янында яңа гына студент еллары белән саубуллашкан кыз балага туп-туры Татарстан китап нәшриятына эшкә урнашу гаҗәбрәк тоела. Нәшриятның да, чагыштыру өчен әйтсәк, «тимерчелегенә», ягъни корректорлар бүлегенә. Безгә китап чыгару турында укыганда аңлатучы да, сөйләүче дә булмады. Бик кирәк булган икән бит. Люция эшли башлаган көннәрендә бу эшне укытучының дәфтәрен тикшерү кебегрәк аңлады. Ләкин бу гаҗәп катлаулы, бар кеше дә булдыра алмый торган һөнәр иде ул чакта. Люцияне нәшриятның корректорлар бүлегендә бу эшне җитәкләүче Суфия Әхмәтова, соңрак Гөлшат Харисова кебек апалары каршы ала. Бүлек нәшриятның иң зур бүлмәсендә урнашкан. 12-13 кешедән торган зур коллектив һәрвакыт зур бүлмәдә, барысы бергә утырып эшләде. Алар бүлмәсе 4нче катта, бик күп гөлле бүлмә булып, анда эшләүчеләр үзләре дә эшкә бик матур киенеп йөри иде. Без алар бүлмәсенә кирәргә кыймыйбыз, Люцияне чакырып кына чыгарабыз, хәл белешеп, тиз генә саубуллашабыз. Әллә ничек килешми кебек. Корректорларның күбесе инде өлкән. Кырыгынчы еллар башында ук 18-20 яшьләрендә үк килеп эшли башлаганнар. Нәшриятның «аяклы тарихлары». Язучы халкын бик әйбәт беләләр. Люция кебек яңа эшли башлаган кызларга кызыклы вакыйгаларны бик тәмләп сөйлиләр.

Бервакыт, әле ул чакта татар газетасы иске имля (гарәп шрифты) белән чыга. Ике язучы очраша: «Нишләп йөрисең?» – ди берсе. Икенчесе: «Нокта кырып кайтам», – ди. «Нинди нокта, ник кырасың?» – ди. Казан кунаклар көтә. Газетаның беренче битендә зур итеп: «Хуш киләсез, Казан кунаклары!» – дип язып куялар. Кунаклар дигәндә «н» хәрефе турысына ике нокта төшә. Бер генә кирәк була. Ике нокта булганда «т» булып укыла шул. 3 көн буена язучыларга бер ноктаны кырырга туры килә. Башта бер дә кызык түгел кебек. Икенче караганда куркыныч. Тәҗрибә, остару тора-бара гына килә. Бу ханымнар, апалар, бер-берсе өчен калтырап, куркып тора. Автор «киез итек фабрикасы Африкага бүләк итеп киез итекләр җибәрә», дип яза икән, бу хата өчен автор гына түгел, барысы да җаваплы. Кайчагында яшьләргә өстәлдә китап-сүзлек, белешмәләрне актарып торасы да юк, эш буенча берәр сорау-мазар туса, өлкәннәр яттан гына әйтеп җибәргәннәр. Әмма иң мөһиме – нәшрият кешеләренә хас сыйфат – үз эшләрен яратырлар, шуннан тәм табалар. Коллективтагы мондый мохит, аларның уңай мөнәсәбәте хезмәт юлын яңа башлаган яшьләргә тәэсир итми калмый. Люция Гыйззәтуллинаның нәшрият эшен, аның кешеләрен ярату, хөрмәт итү әллә каян түгел, әнә шул корректор ханымнар мәктәбеннән күчә. Әле дә ул корректор ханымнар белән эшләгән чакларын сагынып туя алмый. Ул шул бүлектә эшләрмен дә эшләрмен, дип уйлый. Ләкин аны тиз күреп алалар. Ул баскычлап үсә. Кече мөхәррир итеп күчерәләр. Аннары мөхәррир. Монда инде зур-зур, дәрәҗәле агайларның әдәби әсәрләрен редакцияли. Матур әдәбият бүлеге редакторы Кыям Миңлебаев чын мәгънәсендә остаз була. Остаз ни кушса, Люция ханым карусыз үти, чөнки ул булдыра. Бер-бер артлы тәрҗемә китаплары чыгып тора: С.Радзиевская «Урман экияте», Н.Сладков «Баллы яңгыр», рус, казах халык әкиятләре, Н.Толстой «Хаҗи Морат», Һ.Андерсен «Уникe сәяхәтче», Н.Гоголь «Борын»... Менә шул хезмәтләренә таянып, 1999 елда аны Татарстан Язучылар берлегенә кабул итәләр. Бу эшне дә тәрҗемәчеләрнең җитәкчесе, мөхәррир Кыям Миңлебаев башлап йөри. Бу еллар – «Мәгариф» нәшриятында эшләгән чоры, татар китабының иң бәхетле еллары. Бер туктаусыз татар китаплары чыгып тора. Укучы баланы тәрбияли, үстерә торган китаплар серияләп басыла. «Хәзинә», «Милли әдәбият китапханәсе», «Бала күңеле», «Балачак әдипләре», Г.Тукай, А.Алиш әсәрләре җыентыклары һәрвакыт яратып кабул ителә.

Г.Тукайның Люция Гыйззәтуллина төзегән «Сагыныр вакытлар» китабы кат-кат басылды. Гел таралып тора. Аның өчен иң кызыгы да, катлаулысы да язучылар белән эшләү, аннары редакцияләү. Бүлек мөдире булып алган Л.Гыйззәтуллина Татарстан китап нәшриятында 40 ел эшләү дәверендә бик күп авторлар белән аралашырга, әсәр буенча кара-каршы утырып эшләргә туры килә. Кайвакыт кульязмаларны редакцияләгәндә төрле кызыклы хәлләр дә килеп чыккалый.

Күренекле язучыбыз Айдар Хәлимнең 10 ел буена язган «Хунвэйбин» дигән тарихи публицистик романын редакцияли башлый ул. Һиҗрәткә дучар булган милләтебезнең ачы язмышларын сурәтләгән бу әсәр гаять үзенчәлекле: ул фаҗигале вакыйгаларның кайсын сатира, кайсын сарказм белән, үтеңне сытарлык итеп тасвирлаган, геройларның характерлары да күңелне айкап ала. Кайбер шәхесләр, хакимият кешеләре авторның усал теле белән сурәтләнеп, кискен тәнкыйть утына эләгә.

Инде Айдар Хәлим белән ни эшләргә дип йөргәндә, Люция ханым бер «хәйләгә» бара: «Айдар абый, Сезнең бу романга Тукай премиясе бирүләре бар бит. Китап чыккач, комиссия бик каты тикшерәчәк. Сүзгә кергәнче, кайбер хәтәр урыннарын кыскартыйк микән әллә?» – дип әйтеп карый. Айдар ага исә: «Тукай премиясе дип, әсәремне печтермим!» – дип, җавапның төгәлен бирә, сүзсез дә аңлашыла. Болай булгач, башка дәлилләр көчсез.

Янә олуг бер шагыйребезнең «Равил Фәйзуллин. Заман. Иҗат. Шәхес» китабын редакцияләү бәхете дә эләгә Люциягә. Эш барышында редактор тәкъдим иткән һәр төзәтүгә, һәр сүзгә авторның ничек игътибарлы, таләпчән булуына Люция таң кала. Сорау туса, Равил Фәйзуллин бөтен эшен ташлап, шундук үзе килә. Язучыны болай мәшәкатьләүдән уңайсызлана Люция. Авторның бер килүендә: «Равил абый, икенче болай эшләмәгез инде», – ди. Р.Фәйзуллин: «Мин үзем белермен, ничек эшләргә икәнен!» – дип сүзне өзә. Ә инде китап чыккач, автограф язып бүләк итә: «Гомеремдә күп китаплар чыгарып, байтак редакторлар белән эшләргә туры килде. Әмма бу кадәр тырыш, фидакарь затлы күргән булмады». Мондый олпат затлардан шундый сүзләр ишетер өчен генә дә язмышка рәхмәтле булырлык шул...

Бүген Татарстан китап нәшриятының хәле – милләт хәле, татар теле язмышы кебегрәк. Бер урында 40 елдан артыграк эшләгәч, Люция ханымны бүгенге директоры Илдар Сәгъдәтшин зурлап, хөрмәтләп озатты. Люция ханым сүзен кыска тотты: «Яратып эшләдем, яратып китәм», – диде.

Бүген ул сагынып яши. Гомер буена бергә эшләгән хезмәттәшләрен, китапларын сагына. Бакчасын ярата, китаплар ярата. Ил язмышы, китап язмышы уйларында.

Фәния ХУҖАХМӘТ,
«Татар мөселман календаре»
мөхәррире.

Тагын «Идегәй» дастаны турында



Татарстан Фәннәр академиясендә «Татар гыйлеме» яшьләр фәнни мәктәбе кысаларында «Татар халык дастаны һәм Нәкый Исәнбәт» дигән күргәзмә дә тәкъдим ителде. Аны КФУ доценты, әдәбият белгече Миләүшә Хабетдинова әзерләгән.

Белгәнебезчә, күренекле татар язучысы, шагыйрь, драматург, галим-филолог һәм фольклорчы, Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләге иясе, Татарстанның Халык язучысы Нәкый Исәнбәтне бурлыкта гаепләүчеләр булды. Миләүшә Хабетдинова Нәкый Исәнбәтнең «Идегәй» дастаны буенча эшчәнлегенә кагылышлы архив документларын өйрәнеп, күргәзмәгә үзе тапкан, шәхси һәм Милли архивта сакланган документларның күчермәләрен (алар беренче тапкыр Тинчурин театры фойесына куелган «Татар халык дастаны һәм Нәкый Исәнбәт» күргәзмәсендәге тамашачыга тәкъдим ителгән иде) урнаштырган. Витринада Нәкый Исәнбәтнең «Идегәй» дастанына авторлык хокукларын раслаган документлар тәкъдим ителә. Алар арасында беренче мәртәбә җәмәгатьчелеккә чыгарылганнары да бар. Әйтик, Нәкый Исәнбәтнең ике хаты табылган. Нәкый Исәнбәт язучы Әхмәт Фәйзигә Мәскәүгә җибәргән дастанның язмышын белергә кушкан. «Хатта Әхмәт Фәйзи Нәкый Исәнбәткә, автор графасында аны күрсәтмәгәннәрен хәбәр итә. Чөнки Н.Исәнбәт – фольклор экспедициясе һәм «Җидегән» эше аркасында да күзәтүдә. Һәм моннан тыш «портфель» да скандалы бар. Ә.Фәйзи хатында Н.Исәнбәтнең үзенең авторлык хокуклары турында хатны галимнәргә, Соколов, яки Антопольский, редакция хезмәткәрләренә, галимнәргә язарга киңәш бирә. Икенче хатында ул инде сөенеп-шатланып, текстның экспертиза үткәнлеген, аны олуг галим тюрколог-лингвист Владимир Гордлевскийның, эпосларның комиссия рәисе Соколовның хуплавы турында яза. Нәкый Исәнбәт үз эшенең һәр битендә кайдан нәрсә алганын күрсәтеп барган. Туксанынчы еллардагы галимнәр бу сылтамаларны юк итеп чиста текст кына бастырганнар. Минем документлар аша Исәнбәтнең чисталыгын күрсәтәсем килә», – ди М.Хәбетдинова.

Күргәзмәдә шулай ук Н.Исәнбәтнең авторлык хокукларына бәйле суд эшләренә карый торган документлар белән дә танышырга мөмкин. Бу җәһәттән аның судка язылган гаризасы игътибарны җәлеп итә. Ул елларда Исәнбәт «Идегәй» өчен акча таләп итә, шуңа бастырырга ирек бирми, дип сүзләр йөри. Әмма документларда Н.Исәнбәт текстологик фәнни эшенең бернәрсәсен дә үзгәртмичә бастырырга соравы ачык күренә. Чөнки аның фәнни аңлатмаларын юкка чыгарганнар, шуның өчен текстны аңларга инде авырлашкан була. Витринада Нәкый аганың Язучылар берлеге идарәсенә авторлык хокукларын яклауда ярдәм итүләрен, «Казан утлары» журналына һәм Татарстан китап нәшриятына аңлатма бирүләрен сораган хаты да бар. Судлар була. Әмма Татарстан Югары суды Н.Исәнбәтнең авторлык хокукларын юк итә. Ул вакыттагы Татарстан мәдәният министры Булат Гыйззәтуллин (Исәнбәтнең улы) һәм Йолдыз Исәнбәт, Мәскәүгә барып, Югары судның карарын юкка чыгара.



Комиссия әгъзасы Миркасыйм Госманов 1990 елларда, Алтын Урда темасыннан куркып, Нәкый аганы бик каты рәнҗетүләре турында әйтә. Титулда, партия кушуы белән генералитет комиссиясе төзегән исемнәр, шулай ук бу эшкә бернинди өлеш кертмәгән кешеләрнең исемнәре бар, ә Исәнбәтнең контр титулда исеме булмый. «Ул анда автор хокуклары буенча торырга тиеш иде. Суд карарында «Идегәй»нең халык дастаны булуын, ә менә Самарада урнашкан авторлык агентлыгы (ул елларда Татарстан өчен дә җаваплы), Нәкый аганың авторлык хокукларын яклап, аның хезмәттә 20дән артык чыганакны тәртипкә китереп, диалектик сүзләрдән арындырып, бер стильгә китереп төзелгән текст булуын, гомумән, әсәрдә зур тестологик хезмәт күрсәтелүен белдерәләр һәм Н.Исәнбәтне яклап чыгалар», – дип сөйләде галимә.

Соңгы елларда башкорт галимнәре үзләренең көндәлек матбугатта чыккан мәкаләләрендә, имеш татар галимнәре бутап, татар дастаны дип, башкорт вариантын кулланалар, дип язалар. Миләүшә Хәбетдинова, әлеге мәсьәләгә дә җавап итеп, шулай ук чыганаклар тәкъдим итә. «Алар белән танышсаң, Нәкый аганың 1928 нче елда башкорт комплексլы экспедициясендә әгъза буларак дастанның өч вариантны язып алуын, аларны өйрәнеп, текстологик хезмәтне ясап, Академик үзәккә үзенең фәнни мәкаләсе һәм аңлатмалары белән тапшыруын күрәсең. Әмма Н.Исәнбәт үзен типтәр, татар дип язгач, аны бастыруга каршылыклар тудыра башлыйлар. Ләкин Академик үзәктә аның хезмәте рецензия узган һәм планга кертелгән. Мин аны таптым. Әмма дастан 10 ел бастырылмыйча торган. Н.Исәнбәтнең Язучылар берлегенә язган ачык хаты моны раслый. Нишләп 10 ел дәвамында минем бастырмыйсыз, дип язган. Шуннан ул татар «Идегәй» дастанын бастыргач, башкортлар «Идүкәй белән Морадым»ны дөньяга чыгаралар. Нәкый аганың 1928 нче елдан тир түккән хезмәте документлар аша ачык күренә», – диде Миләүшә Хәбетдинова.





Сөембикә КАШАПОВА.
Автор фотолары.

Рөстәм ЗАРИПОВ

Кеше беркайчан да ялгыз түгел, Күләгәсе һәрчак үзе белән...

* * *
Күз атышып йөрдек озак.
Көне житте. Кочаклаштык.
... Якыннанрак танышкач,
Тыныч кына ераклаштык....

* * *
Әллә ниләр өйрәтәләр, син түз, мин түз,
Сабыр савытлары тулмасын...
Дөрес, күпне белү әйбәт... Әмма ләкин
Берсен дә эшлисе булмасын!

* * *
Өйрәтелгән этләр озак ашый,
Тәмен тоеп,ягъни сузыбрак;
Өйләнгән ир-атлар озаграк яши,
Өйләнмәгәннәре – кызыграк....

ТӨП ЫСУЛ

Беләсеңме, белмисеңме
Саныйсың, барлыйсың,
Башкаларга аңлатканда,
Үзең дә аңлыйсың...

НИШЛӘРГӘ?

Күз чыгыла кояш яктыртканда,
Кояш баткач, янә рәтләп күрми.
Аякны чылатсаң – тамак шешә,
Тамакны чылатсаң – аяк йөрми...

ХӘЗИНӘ

Башында җил уйный, шуңа уйлары саф,
Бер дә төшми усал телләрдән,
Ул бит күпләр өчен зур хәзинә,
Баш ваталар кайда күмәргә...

ДИАЛОГЛАР

* * *
(Мәчеттән кайтып барышлый)

– Әллә кайчангы гөнаһлар борчый,
Алар искә төшә, торып-торып;
– Яңа гөнаһлар кыл, агай-эне,
Алар искеләрен оныттырыр....

* * *
(Кадрлар бүлегендә)

– Ник сөйрәлүчене күтәрәсез,
Канатлыны читкә этәрәсез?
– Чөнки бу очракта ялгыш китми,
Шуышучы башка кәкәй итми.

* * *
(Туктатып, аңлашу)

– Нишләп карашыңнан сагыш саркый?
Ник йөрисең болай күбенеп?
– Кара көнгә, дип күп акча җыйдым,
Инде көтәм шуны өзелеп.

* * *
(Ихлас киңәш)

– Кайсына өйләним икән, әни,
Берсе шактый тулы тәнле, берсе арык.
– Тазасын ал, кыш көне җылытыр,
Җәен күләгәләр, булма сарык!

ТҮРӘ СУКРАНУЫ

Акча түләми һава сулыйсыз,
Тискәре уйларны куймыйсыз.
Бушлай укыйсыз, дәваланасыз,
Бушлай эшләгәнгә дулыйсыз...

* * *
Аз түләүле авыр эшкә
Бик ансат урнашу;
Күп түләүле «кәттә»сендә
Төп максат – урлашу...

* * *
Югары урынны яулаучылар
Нинди генә түбәнлеккә бармый
Максатлары – кесә калынайту,
Армый-талмый...

* * *
Уңышлы түрәләр бар да бериш,
Сине акыллыга санап эшне йөкли.
Шыр тилегә санап түли хезмәт хакын,
Анысын да күп, ди....

БЮРОКРАТ

Кирәк чакта тилегә салыша,
Күрә торып «күрми»,
Ишетмәгән – белми,
Кызык була – көлми...

Ярты сүздән барсын да аңыша,
Әмер бирсә түрә:
Кызык түгел – көлә,
Сүздән гөлләр үрә....

* * *
Кеше суламыйча яши алмый,
Һәм бу һәркем өчен ачык ласа;
Ә һава турында онытабыз,
Кемдер вакыт-вакыт сасытмаса....

* * *
Карьераны ясый уртакуллар –
Тормыш моны мең кат кабатлады...
Талантлыга өскә үрмәләргә
Гел комачау итә канатлары...

ИХ, ЯШЬ ЧАКЛАР, ЯШЬ ЧАКЛАР...

Ахмаклыклар эшләр өчен
Дәрт кирәк, дәрман кирәк.
Гомер уза, күлмәк туза,
Ахмакланыла сирәк...

ДУСЛАР

Сораштыра калсаң
Бар да шыттыралар,
Балта сораганга
Шөшле тоттыралар,

Берни сорамасаң,
Көеңне көйлиләр,
Берни сорашмасаң,
Дөресен сөйлиләр.

КИҢӘШЛЕ ЭШ ТАРКАЛМАС

Гамил Афзалның «Мәүҗидәттәй»е дулкынында

Гайшә түти, кызым, ди-ди
Чүгә-чүгә бии,
Гаиләсе нык булсын, дип,
Колагына төйи:

– Кызым, ирең соңлап кайтса,
Ал кулыңа уклау,
Дөрес юлга тиз бастыра
Уклау белән тукмау...

Әгәр үзең тоткарлансаң,
Авыз ачып торма,
Хатын-кыз – баш, ир-ат – муен
Бүгенгесе чорда...

Гайшә түти киленен дә
Кызыдай үз күрә,
Иреннәрен бөрә-бөрә
Дөрес киңәш бирә:

– Килен, ирең соңлап кайтса,
Чыраеңны сытма,
Кайда йөрдең, – дип тәфтишләп
Ялганын да тотма...

Күрәчәк гүргә кертә, дип
Борчылып та йөрмә,
Ара төзек калсын, дисәң,
Күп нәрсәне күрмә...

КЕШЕ

Кеше беркайчан да ялгыз түгел,
Күләгәсе һәрчак үзе белән;
Бик куәтле канат куя яки
Егып сала сыңар сүзе белән...

УРТАК ДУЛКЫН

Көне буе бер сүз сөйләшмичә,
Җитәкләшеп йөрү рәхәт бигрәк.
Йөрәкләр уртак дулкында типкәч,
Тагын нәрсә кирәк?..

ЯКИ, ЯКИ ...

Намуссыз кеше саф күңеллене
Риялыга саный,
Кирәк тапса, яңагына ямый,
Йә башмагын ялый...

ИШЕТМӘСӘҢ ИШЕТ

«Ирем өчен җаным тыныч минем,
Ул бит бик уңышлы өйләнде.
Мин тыңлаучан,
һәм үземчә эшлим», –
Дип, күршем хатыны сөйләнде...

* * *
Чак кына салдыммы, ул үз итми,
Аек чакта минем ис китми,
Күптән юл чатында торабыз,
Алмаш-тилмәш авыз ерабыз...

КҮРСӘТМӘ

Түрәләр җыены. Дәве сөйли:
«Чукракларыгыз да ишетсен:
Шундый итеп алдыйк без халыкны,
Үзен бәхетле дип хис итсен!»

АЕРМА

Яшьлекнең киләчәге бар,
Ә картлыкның – үткәне,
Яшьлек – тормыш яшеллеге,
Картлык – шуның бүкәне.

Яшьлек киләчәге картлык,
Төптән уйлап карасаң
Картлыкның үткәне – яшьлек, –
Исәп тигез ләбаса?

Картлык сагына яшьлеген,
Яшьлек тоймый картлыкны.
Картлыкны иярли сагыш,
Яшьлек каулый шатлыкны.

ТЕЛЧЕ ГАМЕ

«Дуслык» дип атала пычкы,
«Дуслык» дип атала сыр,
Киреләй укыйм да аңлыйм:
Аңа сыйган «суд» һәм «кыл».

«Дуслык»ның асыл мәгънәсен
Телим дөрес аңларга.
Шул хакта баш ватып ятам
Сызылып аткан таңнарда...

СӘБӘП

– Төне буе йоклый алмадым, дип,
нык зарланды хатын.
– Намус борчыганда мин дә шулай,
дип аны юаттым.

* * *
Күңел байый, дип кылтайма,
Килә бер көн – ул бөлә.
Бәхет тә әүвәл елмая,
Аннан шаркылдап көлә...

* * *
Кем очраса, шуңа елмаеп уз,
Бозык тешләреңне яматсаң,
Пенсиягә чыккач, озак торма,
Әгәр ватаныңны яратсаң...

* * *
Танышканда канат куйды яры,
Купты давыл, күккә ашты күңел.
Өйләнешкәч мөгез куйды – тагы,
Һәм ул шуннан бирле мүкләк түгел.

* * *
Кыш җиттеме, язны көттек,
Җәй җиттеме – көзне,
Көзен кыш, дип өзгәләндек, –
Аңламассың безне...

һәрбер фасыл әүвәл асыл,
Аннан уңа яме.
Сырлануларың төкәнә,
Сүнгәч гомер шәме...

Михаил Худяков

(Дәвамы. Башы 45, 46, 47 нче саннарда).

Казаннарның Әрмәнстан белән сәүдә итүе хакында Герберштейн да телгә ала (Зап. О Моск., с.150). Проф. Н.Ф.Высоцкий Казан әрмәне авызыннан мондый риваять язып алган: «Казанда татарлар хакимлек иткән заманда бирегә, хәзерге Суконный бистәсендә, гаиләләре белән күп әрмән сәүдәгәрләре яшәгән. Үзләренең чиркәве булган. Хәзерге Георгий чиркәве урынында. Явыз Иван Казанны басарга килгәч, татарлар патша гаскәренең берничә һөҗүмен кире каккannan соң, берничә әрмән урыс станына килгән. Кирмәннең бәреп керер өчен зәгыйфь урыннарын, әгәр дә патша аларны юмарт бүләкләсә, күрсәтәчәкләрен әйткәннәр. Патша риза булган һәм серне белгәч, шәһәрне тар-мар иткән. Җиңү тантанасыннан соң айныгач, Иван әрмәннәрне искә төшергән, һәм иске аркадашларын саткан кешеләрнең яңа дусларны да сату мөмкинлеген уйлап, әрмәннәрнең барысын да юк итәргә боерган. Явыз патшаның бу әмерен алданрак ишетеп, әрмәннәрнең байтагы яшерен рәвештә Идел буе шәһәрләренә, аеруча Әстерханга качкан. Анда, янәсе, әлегә кадәр шундый бер качакның варислары «Казанский» фамилиясен йөртә икән. Әлбәттә, барлык әрмәннәр дә качып котыла алмаган, калганнарын патша әмере белән үтереп бетергәннәр» (Н.Ф.Высоцкий. «Немецкая Куртина» – древнее армянское кладбище в Казани» (Известия О-ва Археологии, Истории и Этнографии при Каз.Ун-та, т. VII, с.4-5).

1880 елда проф. Н.Ф.Высоцкий Өченче тауда – Бартоло йорты бакчасында әрмән зиратының урынын таба. Бу урын «Немец куртинасы» дип аталган. Проф. Высоцкий 6 кабер ташына юлыга һәм ул 4 аерым каберне, 1 шактый ук зур гомуми каберне казып тикшерә. Әрмән язулы кабер ташлары хәзер Казанның үзәк музеенда саклана. Әрмән зиратының табылуы Казанда күп санлы әрмән колониясе булуын раслый. Н.Ф.Высоцкий язып алган риваять әрмәннәрнең Казанда бөтенләй юкка чыгуын аңлатырга омтыла: Казан ханлыгы дәверендә тулы ирекtән файдаланган әрмән сәүдәгәрләре, Казанга һөҗүм вакытында, христиан булар ак, күнелләре белән урысларны яклас алар да, соңрак яңа режимның золымына түзә алмыйча бүтән шәһәрләргә күчәләр. Казан ханлыгы җимерелгәннән соң Шәрекъ белән сәүдә мөнәсәбәтләре өзелеп тора, һәм әрмән сәүдәгәрләре бөлмәс өчен Казанны ташлап китә.

Кораиш бистәсе Болак артында – хәзерге Печән мәйданы тирәсендә утырган. Урыс хөкүмәтенең архиепископ Гурийга 1555 елның 13 августында биргән грамотасында «Кураишево» атамасы телгә алына (Акты Исторические I, N 162, с.299). Битекче кенәгәсендә «Утуч (Үтәш?) мәчетенә каршы Кораиш ныгытмасының капкасы» дигән юллар бар (Писц. Книга, с.50). Бу хәбәрдән күренгәнчә, Кораишта мәшһүр Чапкынның әтисе Отуч бәк салдырган мәчет булган. Әлеге мәчет «Царственная Книга»да да телгә алына; 1552 елда урыс гаскәрләрен урнаштырганда «патшаның үзенә һәм кенәз Володимер Андреевичка Хан болынында Отуч мәчете янында» урын билгеләнгән. Битекче кенәгәсендә телгә алынуына карап, Отуч мәчетенең Казанны алынганда җимерелмәвен, әле 1566 елда да саклануын беләбез. Шәһәр астындагы Бишбалта авылы хәзерге Адмиралтейски бистәсенең көньяк-көнбатышында утырган. Монда әле дә Бишбалта дип аталган татар урамы бар. Әлеге авыл «Царственная Книга»да беренче тапкыр 1552 елның 9 мартында булган вакыйгаларны тасвирлаганда телгә алына: «Бишбалтага воеводалар килүгә, Ислам кенәз, тагын Көбәк кенәз, тагын Чура Нарыковның берадәре Галикәй морза воеводалардан алда шәһәргә киттеләр» (Царств. Книга, с.199). Урыс гаскәрләрен Казанга һөҗүм итү алдыннан урнаштыру турында язганда Бишбалтаны «Казан елъязмачысы» (ПСРЛ XIX, с.434), качкан казаннарны эзәрлекләүне тасвирлаганда янә «Царственная Книга» телгә ала (Царств. Книга, с.307).

Казан белән Иделне, хәзерге кебек үк, язын су астында кала торган киң болыннар аерып торган. Кенәз Курбский Идел кичүләрен тасвирлап болай яза: «Казан каласына каршы киң һәм иркен, һәм бик тигез болынга чыктык» (Курбский, с.16). «Казан елъязмачысы» хәбәр итә: «Болактан Иделгә кадәр гаҗәеп киң, гүзәл хан болыны җиде чакрымга кадәр сузыла, күп үләннәр яшелләнеп утыра һәм төрле-төрле матур чәчәкләр үсә» (ПСРЛ XIX, с.119). Болынны «Хан болыны» дип атауларын («Царев луг») «Царственная Книга» да раслый. П.Заринский яза: «Бу төбәктә әле дә Пыяла заводыннан сул якта (ягъни көньякта) Хан күле (Царево озеро) бар. Күлне әлеге исем белән монда җәйге сабанга (Сабан туена) чыккан Казан ханнарына нисбәтән шулай атаганнармы, әллә патша лагерена бәйле рәвештәме – ачыклавы кыен» (Заринский, с.212, прим. l).

Проф. Н.П.Загоскин беренче фаразны тулысынча кабул итә: «Казан ханнары монда «сабан» бәйрәменә чыкканга, бу болынны Ханныкы дип атаулары бик мөмкин (сабан туе хәзер дә моннан ерак түгел төштә үтә) (Загоскин, с.108).

Шәһәр белән Бишбалта арасыннан, Хан болыны буйлап, Казан елгасының бер тармагы Бакалды янында Иделгә койган. Бу тармак Эчке Казан дип аталган. Гәлеч юлында Казан суы аша күпер булган, аның турында кенәз Курбский әйтеп үтә (Ист.кн.вел. Моск., с.18). Казан елгасының тамагын «Тирән Үзәк» дип атаганнар. Бу атама чыганакларда күп тапкырлар кабатлана (ПСРЛ VI, с.306; XIX, с.413; Царств. Книга, с.262). Иделдә Казан елгасының тамагына каршы урысча «Гостиный» дип аталган утрау була. Герберштейн аны «Сәүдәгәрләр атавы» дип ачыклый. Бирегә ел саен халыкара ярминкә уздырганнар. Иделнең теге ягында Ослан таулары калкып торган. Ул заманда алар, мөгаен, урман белән капланган булгандыр. Иң биек түбә – Ослан – нәкъ Казан елгасының тамагына каршы, ул Идел үзәненнән 70 сажинга биектә. Ослан тавыннан Казанга һәм тирә-юньгә гаҗәеп манзара ачыла. Казан ханлыгы заманында башкала куе урманнар белән чолгап алынган. Иң якын урман Арча кыры ягында булган. Мондагы ерганаклар белән чуарланып беткән җирләрдә әлегә кадәр йортлар салынмаган, ул ылыслы урманнарны кискәннән соң үсеп чыккан яфраклы агач үсентеләре белән капланган. Әлеге җирләр Рыбноряд ерынтысы беткән төштә үк (Износков һәм Панаев бакчалары) башлана да Кабанга (Осокин агачлыгы) һәм Казан елгасына таба (Институт агачлыгы һәм Неелов агачлыгы – Новиков дачасы) сузыла. Үсеп чыккан яфраклы агачларның шактый өлеше шәһәр читендәге «Урыс һәм Немец Швейцариясендә» сакланган. Казан елгасының теге ягында, Курбский әйткәнчә, зур урман («велик лес») – нарат урманы булган, Кизик монастыреның агачлыгы – шуның калдыгы. Кырыгынчы завод бистәсеннән башланган казна урманы хәзер дә берничә дистә чакрымга сузыла.

Башкалага якын авыллар көньякка урнашкан. Болар – Кабан күле ярындагы Колмәмәт (Кол Мөхәммәд) (хәзер Дальне-Архангел бистәсе) һәм татар Казаныннан өч чакрым ераклыкта, Арча кыры артындагы калкулыкларда урнашкан Әхмәд авыллары; соңгысын хәзер Әмәт (Аметево) дип кенә йөртәләр. Авылларның икесе дә 1566-1568 елларга нисбәтән Битекче кенәгәсенә теркәлгән.

Казанның гомуми күренеше

Кенәз Курбский Казанны тасвирлап болай яза: «Ул урын (кала) ике өлештән гыйбарәт, берсе үзәндә урнашкан, икенчесе тауда, ә өченче өлеше еракта, үткелдә». Бирегә Кара күл инкүлеге һәм Черек күлләр уйсулыгы турында сүз бара. Алар Воскресенски һәм Кремль калкулыкларын Театр калкулыгы белән Иске Шәһәрлектән аерып торган. Боларның ярлары тәңгәл түгел – көнчыгыш як көнбатышныкына караганда сөзәгрәк булган. Воскресенски калкулыгы Театр һәм Иске Шәһәрлек калкулыкларына караганда күпкә биек. Иске шәһәрлек калкулыгы бүтәннәрдән иң тәбәнәге. Барлык калкулыкларның да көнчыгыш итәге көнбатыш яктагыга караганда текәрәк.

Кремль калкулыгының өслеге хәзер шактый тигезләнгән; аның сырты көнчыгышта Черек күлләр ягындагы текә ярлы итәге яныннан үткән, Болакка таба исә өслек акрынлап түбәнәя барып кинәт текә яр хасил иткән, шуның чите буйлап кирмән диварларын торгызганнар. Хәзерге вакытта калкулыкның Кремль урамыннан көнбатыш диварга төшкән итәгенә катлам-катлам туфрак утырган, шуңа да кремль эчендәге туфракның өслеге дивар сырты белән тигезләнгән (Спас монастыре ермагында һәм Хәрби училище ишегалдында). П.Заринский яза: «Преображенски капкасы (элекке Төмән капкасы) хәзерге вакытта бөтенләй туфрак белән күмелгән, аның түбәсе җирдән бер аршынга гына чыгып тора» («Очерки др. Казани», с.138-139). Элек болай булмаган, һәм Киприан белән Юстина чиркәвеннән Преображенски капкасына иркенләп үтә алганнар. Кремль калкулыгының көнчыгыш өлешеннән ермак үткән. П.Заринский бу хакта болай хәбәр итә: «Кремль тавының уң (көнчыгыш) кырыендагы төшү юлына төньяк-көнчыгыштан Таҗик ермагы якасының тармаклары килеп тергәлгән, алар язгы ташулардан һәм яңгыр суларыннан һәрвакыт ишелеп торган; су төшә торган шундый юлларның берсе Дмитриев капкасына таба юнәлеш алган. Ул әле дә саклана. Бу ермак аша Дмитриев капкасына каршы күпер салынган булган (Заринский, с.139). 1566 елга нисбәтән Битекче кенәгәсендә әлеге күпер телгә алына (Писц. Книга, с.34). Воскресенски калкулыгының сырты көнбатыштагы итәккә караганда Кара күл инкүлегенә бераз якынрак булган. П.Заринский яза: «Күптән түгел суүткәргеч һәм газ торбаларын сузу өчен урамны казыганда без моңа инандык: калын

● Казан кирмәне, XIV гасыр. Фиринат Халиков картинасы.

китабыннан өзекләр

пычрак катламы һәм төрле урам чүпләренең калдыклары таш күперчектән (Таҗик ермагы аша) уңга, сәүдә рәтенә таба өелгән иде, ә Воскресенски урамының Шәһәр Җәмгыяте һәм Апаков йортлары торган сул (көнчыгыш) өлеше тыгыз балчык катламыннан гыйбарәт иде». (Заринский, с.158-159). Калкулыкның өслеге сыртыннан Болакка таба башта җәй белән генә түбәнәя барган (бу авышлыкның эзләре университет ишегалдында, төп капка белән обсерватория арасында сизелә), аннары итәге кинәт кенә түбән төшеп киткән, кирмән диварлары шуның текә яры өстеннән үтә. Тәртипкә китерелгән урыннардан Кара һәм Мунча күлләре арасындагы мәйданны күрсәтергә мөмкин. Хәзер биредә (цирк белән Кара күл арасында) биек туфрак өеме; элек ул булмаган, бу урын сазлавыклы түбәнлек буларак билгеле, моннан Воскресенски калкулыгының текә итәгенә күтәрелгәннәр.

Борынгы кирмәннән читтә булган Кабан һәм Болакның ярларына игътибар итик; Кабанның көнбатыш яры көнчыгыштагыдан шактый биек; Болакның да сул яры башланган төшендә калкурак (Печән урамы тирәсендә) һәм текә якалы (Мәскәү урамыннан), ә Болакның тамагына якынайгач сул яр түбәнәя һәм сазлана (Юеш урам тирәсендә), ә уң яктан аңа бу төштә Кремль калкулыгының итәге орынып кына тора.

П.Заринский, XVI гасырдагы Казанны тасвирлаганда, яза: «Ул чакта Казан борынгы шәһәрләргә хас бөтен кимчелекләргә ия булган: урамнар дөрес сузылмаган, төп урамнарны күп санлы чапыраш тыкрыклар кисеп үткән, аларда йортлар туры сызык хасил итмәгән, ә бер-берсенә ян белән торганнар, шул рәвешле тыкрыкларда һәм төп урамнарда йортлар янәшәсеннән читкә тупик дип аталган, камил булмаган өчпочмак яки ябык кумырык шәкелендәге тирән иңкүлекләр сузылган. Бигрәк тә мәйданнар дөрес урнашмаган. Урамнар тар, сикәлтәле булган, ерганаклар белән өзелгән, алар аша калтырча басмалардан үткәннәр; йортлар тигез булмаган, урамның тигезсезлегенә бәйле рәвештә әле калкып торган, әле уйсулыкка поскан» (Заринский, с.156). Татар дәверендә Казан күренеше җанлы, табигый булган, ермакларның хәтфә үләнгә төренгән текә һәм кырку, ә кай төшләрдә сөзәк ярлары шәһәргә аерым бер ямь өстәгән. Шәһәр уртасында күлләр җемелдәп яткан – Казан суга бай булуы белән аерылып торган, Кара күл иңкүлеге һәм ерынтылар шәһәрнең бер өлешен бүтәннәрдән аерган, арага йортлар салынмаган, шуңа да калкулыклардагы төркем-төркем биналар әйтерсең лә аерым шәһәрчекләрне хасил иткән.

Казанның күренеше хәзер бөтенләй үзгә – Кремльнең таш диварлары, машлар, чаң эленгән биналар элек булмаган. Каланың өске өлешен, Болак тамагыннан Рыбноряд ерынтысына кадәр, машлар һәм капкалар белән бүленгән агач дивар урап алган. Дивар тирәли күперләр эленгән урлар казылган. Кремль калкулыгында сарайларның һәм мәчетләрнең таш пулатлары калкып торган, шәһәрнең башка өлешендә исә йортларны асылда агачтан салганнар. Алар калку урыннарда төркем-төркем булып урнашкан, ермакларның сары балчыклы якалары, яшел чирәмле үзәннәр, көзгедәй ялтырап яткан күлләр белән бүленгән. Йортлар хасил иткән кәкре, буынтыклы тыкрыклар хәзер Казан урамнарыннан күбрәк булган. Ул тыкрыкларны хәзерге урамнар белән тәңгәлләштерү мөмкин түгел, әмма бу урынның үзенчәлеге төп сызыкларның Кремль һәм Воскресенски урамнары буйлап Арча капкасына таба сузылганын фаразларга ярдәм итә. Бертөрле агач йортлар янәшәсендә биек манаралары чатырлап эшләнгән мәчетләр калкып торган. Өлкәнең Бәрәңге, Әтнә кебек хәзерге зур авыллары татар дәверендәге Казанның кыяфәтен күзалларга ярдәм итә. Билгән мәйданына караганда, Казанда берничә дистә мең кеше яшәгән булырга тиеш. Зур базарлар, ярминкәләр үткәргәндә аларның саны икеләтә арткан. XVI гасырда Казан Көнчыгыш Аурупадагы иң зур шәһәрләр рәтенә кергән, аңардан Новгород белән Мәскәү генә, ә бәлки Вильно белән Кафа да зуррак булган. Идел буенда исә аңа тиңләшерлек шәһәрне чыганаклар атамый. Кенәз Курбский Казанны Вильно белән тиңләп: «Ә аның мәйданы кечкенә түгел, бәлки Вильноныкыннан бераз кечерәктер» (Курбский, с.27). Үзенең уңайлы җәгърафик урынына – Көнбатыштан Шәрекъкә үткән олы су юлына утырганга күрә Казан бик тиз үсеп китә.

Һава торышы белән Казан мактана алмый: ул монда гел алмашынып тора, кышын чатнама суык һәм кар бураннары интектерсә, җәен мине кайнатырлык эсседән соң кинәт коеп яңгырлар ява башлый, һәм ел тәүлегендә көчле җил чыга. Ләкин елның бер аенда Казан искиткеч гүзәлләнә. Язгы ташу вакытында шәһәр өч яктан су камалышында кала. Бу вакытта бөтен тирә-юнь – күк, су, Идел аръягындагы офыкка тоташкан таулар һәм урманнар тоташ зәңгәр төстә балкып тора. Шәһәр су астыннан калкып чыккан әкияти бер атау булып тоела. Ташыган сулар киң мәйдан биләп еракка – Каспий диңгезенә омтыла. Әлеге айда Казан ханлыгының башкаласы белән үзәнлектә Көнчыгыш Аурупаның бер генә шәһәре дә – Мәскәү булсынмы, яисә Бакчасараймы, Вильномы, Әстерханмы, Сарайчыкмы, – берсе дә ярыша алмаган.

Казан татарларының төзү сәнгате

Һиҗри 959 елның 13 шәввәлендә чит ил баскынчылары Казан ханлыгы башкаласына җиңүчеләр булып аяк баса. Казанны яклаучылар сугышта һәлак була. Ядегәр хан әсирлеккә эләгә, татарларның гаять аз өлеше генә, чолганыштан ерып чыгып, Казан суы аръягындагы урманга китә. Баскынчылар җиңелүчеләрне шул хәтле кансыз рәвештә юк итәләр – моны фәкать борынгы ассириялеләрнең шәфкатьсезлеге белән генә тиңләү мөмкин.

● **Казан кирмәне, XVI гасыр. Фиринат Халиков картинасы.**

Күңелсез булса да, митрополит Макарий хөкүмәтенең казаннарга өчләтә мәрхәмәтсез булуын әйтергә туры килә: 1) Казанны алганда ир-ат затыннан булган һәммә кеше үтерелә, 2) Казанда яшәүчеләрнең барысы да шәһәрдән Болак елгасы аръягына куып чыгарыла, 3) Казан мәчетләре җимертелә. Шәһәрне тулысынча талыйлар, халкын кыйнап-изеп ташлыйлар, һәм яңа хуҗаларның вәхшилеге шул дәрәҗәгә җитә ки, шәһәрдәге тарихи биналар бөтенләй юк ителә – хәзер аларның эзен табуы да бик кыен...

Исән калган кешеләрнең һәммәсен шәһәрдән куып чыгару да көтелмәгән вәхшәт була. Татар Казаны юк ителә, җир өстеннән себереп түгелә. Хәзер инде урыс шәһәренең киң урамнары сузылган, чиркәүләре һәм монастырьлары кукыраеп утырган калкулыкларда кайчандыр татар каласының шау-гөр килеп яшәвен, татар йортларының кысылып урнашуын, мәчет манараларының калкып торуын күз алдына китерүе дә кыен. Казанның хәзерге татарлар яши торган өлешен ханлык дәверендәге башкала белән һич тә тәңгәлләштереп булмый – ул яңа, буш яткан җирләрдә пәйда булган үзенә бер аерым утрак урын... Хәзерге вакытта Казанның татар өлеше электр яктырткан киң урамнарында трамвайлар йөреп торган Аурупа шәһәрен хәтерләтә. Фәкать базар гына үзенең милли төсмере белән безне Шәрекъкә кайтаргандай хис калдыра.

Казан ханлыгы башкаласының төс-кыяфәте нинди булганлыгын күз алдына төгәл китерү читен, чөнки шәһәрдә ул дәвернеке икәнлеге тәгаен билгеле бер генә архитектура корылмасы да сакланмаган. Казанның борынгы йөзен шул дәверләрне хәтерләтүче кайбер әйберләрне барлый-барлый гөман кылып һәм хәзерге татар төзү сәнгатенә карап кына бераз чамаларга була. Безгә ул дәвердән татар Казанындагы архитектура корылмалары турында сөйләүче бизәкле ике таш кыйпылчык кына килеп җитә алган, алар, 1861 елда Кремль калкулыгында табылып, хәзер Казан университетының география кабинетында саклана. Болар ниндидер бина йөзлегенең өлешләре, бина катлаулы геометрик шәкелдәге кабарынкы гарәби нәкышләр белән бизәлгән булган. Бу кыйпылчыкларга бик тә охшаш нәкышләрнең төсмер-калдыкларын Болгар каласындагы «Кара пулат»та күрергә мөмкин. В.И.Корсунцев рәсемнәренә нигезләнеп, «Казанский музейный вестник»та бастырып чыгарылган «Дүрткел»нең көнчыгыш һәм көнбатыш ишекләрендәге таштан уеп ясалган гарәби бизәкләр дә шуларны бик хәтерләтә (Каз. муз. вестник, 1920, № 5-6, сс. 65, 80). Шушындый охшашлыклар казаннарның төзү сәнгате үз заманында фарсы сәнгатенең дәвамчысы булып саналган болгар архитектурасы белән тыгыз бәйләнгән икәнен фараз итәргә мөмкинлек тудыра. Моннан соңгы чагыштырулар безне Казан төзү сәнгатенең турыдан-туры болгар архитектурасының дәвамы икәнлегенә, Казан татарларының сәнгате болгар бабаларыннан мирас итеп алынганлыгына тәмам ышандыра.

(Дәвамы киләсе санда).

Ркаил ЗӘЙДУЛЛА тәрҗемәсе.

АЛИШ

Рафис КОРБАН

● Абдулла Алишның әнисе Газизә һәм әтисе Габделбарый Алишевлар. 1914 ел.

(Дәвамы. Башы 46, 47 нче саннарда).

Алишның нәрсә әйтергә теләгәнен бигүк төшенмичә, Оркыя хатны яңабаштан укый башлады. Съезд алдыннан гына Алиш, ни өчендер торган урынын алыштырып, Достоевский урамында бер бүлмәле фатирда яши башлаган иде. Хатының ахырында ул шул фатирын җиһазландыру турында искә алган бугай, союздан күрсәтелгән матди ярдәм хакында язган: «Мин үзем 10-15 сентябрьләргә кадәр Татиздаттан иҗат командировкасына Ютазыга җибәрелдем. 500 сум акча бирделәр, 100 сумлык китапханә бүләк иттеләр. Аннан кала, съезд уңае белән, промтоварлар биргәннәр иде. Шулай итеп, кешене шактый карадылар булып чыгадыр инде бу...»

Хатны кат-кат укып чыкты Оркыя. Укыган саен сагыну көче көчәя барды. Аңа исе китмәгән кыяфәт чыгарып йөрүләре өчен үз-үзен тиргәп тә куйды. Ә бит Алиш яратмаслык егет түгел: чибәр, бөтен кызларны үзенә каратырлык. Тыйнак кына бераз. Анысы да начар түгел, бер караганда...

Хатында язганча, Алишлар тагын берничә көннән командировкадан кайтып та төштеләр. Ләкин Алиш шул көнне үк үзенең Абдулла Әхмәт белән Башкортстанга, Уфага барырга җыенуларын әйтте. Анда Башкортстанның халык шагыйре Мәҗит Гафури нык авырып киткән икән. Язучылар союзыннан әлеге шул ике Абдулланы Татарстан язучылары исеменнән Гафури абыйларының хәлен белешеп кайтуын сораганнар.

– Карагыз анда, башкорт язучылары белән тагын бер «Җидегән» оешмасы төзеп кайта күрмәгез, – дип кисәтте Кави Нәҗми егетләрне, юлга чыгып китәргә җыенган көнне, үзенчә шаярткан булып.

Башкортстанга барып төшкәч, алар язучылар союзын табып, туп-туры союзның рәисе Афзал Таһиров янына керделәр. Кырык-кырык биш яшьләр тирәсендәге бу кеше бернинди дә башкорт булмыйча, үзебезнең Бөгелмә өязендәге Габдрахман дигән авылда туып үскән татар абзые булып чыкты. Үзләренең каян килүләре, нинди эшләр майтарып йөрүләре турында әйткәч, рәис абзый үз янына урынбасарын чакырып кертте. Бу язучы да Габдулла исемле икән.

– Менә, Габдулла, таныш бул, Татарстаннан ике яшь язучы килгән. Икесе дә синең адашларың – Абдуллалар, – диде.

Чама белән Казан кунаклары яшендәге бу егет, аларга кулын биреп, үзен:

– Габдулла Амантаев, шагыйрь,– дип таныштырды. Алиштан бер генә яшькә өлкән булса да, инде союзга керергә һәм рәис урынбасары булып сайланырга өлгергән.

– Егетләр изге эш белән йөри, Мәҗит аганың хәлен белешергә килгәннәр,– диде Афзал агай. – Менә син, Габдулла, адашларың белән үзең дә Мәҗит агайның хәлләрен белешеп кайт әле. Бүген синең эшең шул булыр.

Аларны Мәҗит аганың хатыны Зөһрә ханым каршы алды. Ул Габдулла Амантай белән яхшы таныш иде бугай, өйләренә килеп кереп, сәламнәр алышкач та:

– Габделмәҗит абыегызның кәефе китебрәк тора бит әле,– диде.

– Бу егетләр Казан кунаклары иде. Язучылар. Мәҗит аганың хәлен белешергә килгәннәр, – диде Амантай.

– Казаннан укмыни? Күрмичә китү дөрес булмас инде, алайса. Шулай да мин әйтеп чыгыйм, – дип, ул Мәҗит ага яткан бүлмәгә кереп китте.

Зөһрә ханым шактый ук яшь күренә иде. «Яшь хатыны, ахры», дип уйлап куйды Алиш. Гафури үзе илле дүрт яшьтә булырга тиеш, ә хатыны туташлар кебек кенә иде. Ул ире яткан бүлмәгә кергәндә, ярым ачык калган ишектән, аларга Гафуриның буылып йөткергәне ишетелде.

– Хәлләре бик әйбәт түгел бугай Мәҗит агайның,– диде Амантай. – Авыруы бик җитди – чахотка.

– Тукайныкы шикелле икән. Ул да шул чирдән киткән бит, – дип куйды Абдулла Әхмәт.

Ул арада бүлмәдән Зөһрә ханым чыкты.

– Сез керегез, таныша, сөйләшә торыгыз. Миңа чәй әзерләргә кушты. Бераздан табын артында дәвам итәрсез әңгәмәгезне.

Егетләр Амантай артыннан авыру шагыйрь яткан бүлмәгә атлады.

– Казан кунаклары бар икән. Ничек инде алар белән утырып чәй эчмәскә, – дип каршылады аларны Гафури.

– Әйе, Мәҗит агай, Казаннан сезне күрергә дип яшь язучылар килгән, – дип башлады сүзен Амантай.

Алиш та, Абдулла Әхмәт тә әле язучылар арасына яңарак кына кереп бара торган яшь каләм әһелләреннән санала. Әхмәт Алиштан берничә елга өлкәнрәк булгач, сүзне дә ул башлар дип килешкәннәр иде. Җитмәсә, берничә ел төрле гәзитләрдә журналист булып эшләп алган, хәзер педагогия институтында укып йөри, язучылар белән ешрак аралаша. Мәскәүдә беренче китабын чыгарырга да өлгергән. Ә Алиш үзенә әдәбият белән бәйләнеше булмаган бөтенләй ят өлкәне сайлаган – Җир төзү техникумын тәмамлап, башта Минзәләдә мелиоратор булып, Казанга әйләнеп кайткач, КазГрэс һәм канализация төзелешләрендә эшләдә. Хәзер исә «Техника» дип аталган журнал чыгару белән мәшгуль. Әдәби әсәрләр, бигрәк тә балалар өчен хикәяләр язып, Казан язучылары арасында өметле яшь каләм иясе буларак танылу алган булса да, Гафури хәтле Гафури алдында авыз тутырып сөйләрлек уңышлары әлегә юк дәрәҗәсендә. Егетләр икесенең дә исемнәре Абдулла – берсе Алиш, икенчесе Әхмәт икәнлекләрен әйтеп, Габделмәҗит абзыйларын көлдереп алганнан соң, икесе дә сүзне ни белән дәвам итәргә икән дип, беркадәр югалып калды. Ләкин бу халәттән аларны Гафури агайлары үзе чыгарды:

– Йә, сөйләгез, ниләр майтарып ята анда Галимҗан абыегыз? – диде.

Карт язучының кайсы Галимҗан хакында соравын алар икесе дә шунда ук аңлады, әлбәттә. Гафурины чынлап та Галимҗан Ибраһимов кызыксындыра иде. Син җавап бирәсеңме, дигәндәй, Алиш Әхмәткә карап куйды.

– Галимҗан ага егерме җиденче елдан бирле Кырымда яши, – диде Әхмәт.

– Беләм, аны да шул миндәге чир интектерә. Ул бәхетле, Татарстан хөкүмәте хәленә керде, сәламәтлеген ныгытсын өчен Кара диңгез буйларына җибәрде үзен. Саф диңгез һавасын сулап, таулар һавасының шифасын алып, рәхәтләнеп яшәп ята Ялтада. Миңа менә андый бәхет татымады. Хәлем елдан-ел, көннән-көн начарлана. Озакка түзә алмам, ахры, – диде дә, Мәҗит агай сүзләрен раслагандай, тыны кысылып йөткерергә тотынды. Аның юталләвен ишетеп бүлмәгә Зөһрә ханым килеп керде. Кулына тоткан чынаягында ютәлне йомшарту өчен алдан махсус хәзерләп куйган үлән кайнатмасы иде бугай.

– Эчеп җибәр әле, сулышыңны ачмасмы, – дип, касәне иренең иреннәренә китерде.

Кайнатманы эчкәч, сырхауның хәле бераз яхшырып киткәндәй булды, ул тыныч тын ала башлады һәм сүзен дәвам итте:

– Шундый хәлдә дә ару-талуны белмичә эшли, энә. Минем кебек өендә кырых-кырых килеп ятмый. Дөньяга чыккан һәр мәҗмуга белән танышып, язганнарыбыздан хәбәрдар булып тора. Гади укучы булып кына түгел, аларга матбугатта үз бәясен бирә. Укыгансыздыр, бәлкем, «Совет әдәбияты»ның былтыргы саннарында минем өченче ел Татиздат бастырып чыгарган сайланмаларым турында бик этрафлы мәкалә белән чыкты.

– Укыдык, укыдык, Мәҗит агай, сайланмаларыгызны да укыдык. Хәтерегез калмаса, шундый сорау бирәсем килә, Мәҗит агай: сез ике телдә дә язасызмы ул? Татарча да, башкорт телендә дәме? – дип сорап куйды шулвакыт Абдулла Әхмәт.

Гафури аңа карап елмайды да:

– Татарча гына язам, – диде, кеткелдәп.

– Башкортчага тәрҗемә итәләрме?

– Нишләп итсеннәр. Шул берүк тел бит инде ул. Татарчаны да йөгертеп укыйлар бездә, аның бернинди авырлыгы да юк. Мин бит татар авылында туып үстем. Үзебезнең авыл мәдрәсәсендә, аннары Троицктагы «Рәсүлия» мәдрәсәсендә, бишенче елны Казанга барып, «Мөхәммәдия»дә, алтынчы елны янә Уфага кайтып, «Галия»дә укып, югары белем алдым. Барысында да татарча гына укыттылар.

Әхмәтнең сорауларына җавап биргәннән соң Гафури беркавым тынып калды. Аннары кемнедер исенә төшерергә теләгәндәй:

– Карале, кем соң инде?.. Теге краснармиес формасында йөрүче...

– Кави Нәҗмине әйтәсезме?

– Шул, шул, үзе. Сезнең союзның башлыгы... Ни эшләр бетереп йөри соң? Һаман шул халык дошманнарын фаш итү белән маташамы? Ике туган Вәлидиләрнең башына җитте бугай. Безнең Исәнбәткә теше үтмәде. «Җидегән»не маташтырып караганнар иде моннан качып киткән Газыйм Касыймов дигән бәндә белән. Барып чыкмады бугай ул авантюралары. Мулла малайларын талыйлар. Шуннан сак булыгыз, егетләр. Габдулла, син дә мулла малае бит әле? – диде ул Амантайга карап.

Гафури агайларының юрауларын өч Габдулла да җавапсыз калдырды. Чөнки аларның өчесенең дә нәсел шәҗәрәләре муллалар тамырына барып тоташа. Өчесе дә утызынчы елларга кергәч илдә башланган репрессияләрнең башында зыян күрүчеләрнең мулла малайлары икәнен яхшы белә иде. Алишның да бу елларда әти-әнисенә «чит элемент» дигән ярлык тактылар. Дөрес, аның әтисе Габделбари абзый мулла малае булса да, беркайчан да муллалык итмәгән, патша армиясендә хезмәт итеп кайткан. Мулла кызына өйләнгән-өйләнүен. Ләкин балаларының берсе дә бабалары юлыннан китмәде. Шуңа карамастан, апасы Закирәгә өйләнгән Гали җизнәсен «чит элементлар белән туганлашкан» дип, партиядән чыгардылар. Кантон партия оешмасына барып, хатынының атасы мулла булып тормаган дип аңлатма язып, апелляциягә биргәннән соң гына яңадан партия сафына кайтардылар. Гали җизнәсе дә Габдулаҗан кайнешенә бу мәсьәләләрдә сак булырга, үзенең чыгышын кычкырып йөрмәскә киңәш бирде ул вакытта. Шуңа күрә Алиш Гафури агай соравын да җавапсыз калдырды.

Мәҗит Гафури агай белән шактый озак утырды алар гәпләшеп. Чәй табыны артында да язучыларның хәлләре турында сөйләштеләр. Алиш өчен бу сөйләшүләрдән алып кайткан төп сабак алдагы тормышында үзенең нинди нәселдән килеп чыгуы хакында сак эш итәргә кирәк дигән нәтиҗәгә килүе булды. Гафури шулай ук Алишның балалар өчен язуын хуп күрде. Үзенең дә балалар өчен шигырьләр һәм мәсәлләр язуы турында сөйләде. Киләчәктә аңа иҗатын тулысынча балалар өчен язуга багышларга киңәш бирде.

Уфага китәр алдыннан Алиш Оркыя белән Кырымга барып ял итеп кайтырга дип килешкән иде. Ә Кырымнан алар әниләренә сюрприз ясап, кияү белән кәләш булып кайттылар. Оркыяны ул Яңа бистәгә әниләре йортына илтмичә, командировкага китәр алдыннан гына яши башлаган Достоевский урамындагы бер бүлмәле фатирына алып кайтты. Аларга никахны, авылдан килеп, әтисе Габделбари абзый үзе укыды. Никах мәҗлесенә бөтен туган-тумача җыйналган иде. Көектән дә, Рәҗәп белән Салманнан да әтисенең бөтен туганнары килде. Бары тик Гали җизнәсе генә килә алмый калды. Авыл советы рәисе булып эшләгәч, көзге кыр эшләрен ташлап китә алмаган. Кыр эшләре төгәлләнгәч, соң булса да барыбер килеп, яшь парларны котлап китәргә җай тапты тагын үзе.

Туйдан соң берничә көн үткәч Уфадан Мәҗит Гафуриның вафат булуы хакында хәбәр килде.

(Дәвамы киләсе санда).

Йолдызсыз калган 25 татар каһарманы

(Дәвамы. Башы 47 нче санда).

ИБРАҺИМОВ ИСХАК ИСМӘГЫЙЛЬ УЛЫ

Ибраһимов Исхак Исмәгыйль улы – 1924 елгы, Мамадыш комиссариаты аша чакырылган. 1 нче Белорус фронтындагы 3 нче удар армиянең 1622 нче зенит-артиллерия полкындагы орудия расчетында гвардия ефрейторы булып хезмәт итә. 1945 елның 1 маенда Герой исеменә тәкъдим ителә, ләкин Кызыл Байрак ордены белән генә бүләкләнә.

Исхак Ибраһимовны Герой исеменә тәкъдим итү кәгазе.



Наградной лист

1. Фамилия, имя, отчество ИБРАГИМОВ Искак Исмаилович
2. Звание гвардии ефрейтор 3. Должность, часть, соединение орудийный номер 1622 Армейского Зенитно-Артиллерийского полка

Представляется к званию Героя Советского Союза

4. Год рождения 1924 5. Национальность Татарин 6. Партийность канд.ВКП/б/
7. Участие в гражданской войне, последующих боевых действиях по защите СССР и Отечественной войне (где, когда) Отечественная война с 1942 года
8. Имеет ли ранения и контузии в Отечественной войне ранен -2 раза
9. С какого времени в Красной Армии с 15.3.42 года
10. Каким РВК призван Мамадышским РВК, Татарской АССР
11. Чем ранее награжден и дата награждения не имеет
12. [illegible] к награждению и адрес его семь[и]

I. КРАТКОЕ КОНКРЕТНОЕ ИЗЛОЖЕНИЕ ЛИЧНОГО БОЕВОГО ПОДВИГА.

Участвуя в наступлении на Берлин, тов. Ибрагимов проявил личную храбрость, отвагу и геройство.

29.4.45 г. в р-не Рейхстага тов. Ибрагимов изъявил добровольное желание пройти по тылам пр-ка и водрузить знамя Победы над зданием Рейхстага с группой бойцов перешел через р. Шпрее и, сломив сопротивление немцев, подошел ко 100-200 метров к зданию Рейхстага.

Несмотря на численный перевес пр-ка, тов. Ибрагимов с группой бойцов завязал не равный бой. На помощь смельчакам спешили артиллеристы, но огонь пр-ка был настолько силен, что и танки и орудия, потеряв свои расчеты не могли двигаться дальше. Тов. Ибрагимов, лично пробравшись к орудию, начал вести огонь из 76 мм. пушки по пулеметным точкам пр-ка, уничтожив при этом 3 пулеметных точки и 20 гитлеровцев.

Прямым попаданием снаряда пр-ка, орудие было разбито, тов. Ибрагимов был ранен, но несмотря на это, пробрался к танку и, войдя в него, начал вести огонь по гитлеровцам, которые пытались окружить группу смельчаков, уничтожив при этом 10 гитлеровцев.

Тов. Ибрагимов своими героическими подвигами способствовал водружению знамени Победы над Берлином.

Тов. Ибрагимов достоин присвоения звания Героя Советского Союза.

Командир (начальник) 1622 ЗАП подполковник: /Олиников/

1 мая 1945 г.

САБИРОВ ГАБДУЛЛА БИКТАҺИР УЛЫ

Сабиров Габдулла Биктаһир улы – 1923 елгы, Яшел Үзән комиссариаты аша чакырылган. 274 нче укчы дивизиянең 814 нче артиллерия полкында разведка отделениесе командиры булып, гвардия өлкән сержанты дәрәҗәсендә яу йөри. 1945 елның 3 маенда Герой исеменә тәкъдим ителә, Кызыл Байрак ордены белән генә бүләкләнә.

САТДЫКОВ КАСЫЙМ ХӘСӘН УЛЫ

Сатдыков (Ситдыйков-?) Касыйм Хәсән улы – 1913 елгы, Чистай район комиссариаты аша фронтка озатылган. 2 нче Украин фронтындагы 27нче армиянең 78 нче Запорожье укчы дивизиясендә 458 нче укчы полкта рота командиры, өлкән лейтенант. 1944 елның 4 апрелендә Герой исеменә тәкъдим ителә, Кызыл Байрак ордены белән бүләкләнә.

САФИН ИСЛАМ ИБРАҺИМ УЛЫ

Сафин Ислам Ибраһим улы – 1911 елда Норлат районының Бүрмәт авылында туган, Октябрь район комиссариаты аша чакырылган. 16 нчы гвардия укчы дивизиянең 46 нчы укчы полкында пулемет расчеты командиры, гвардия рядовое. 1945 елның 12 апрелендә Герой исеменә тәкъдим ителә, 3 нче дәрәҗә Б.Хмельницкий ордены белән бүләкләнә. 1992 елда вафат булганнан соң, туган авылы зиратында җирләнә.

ИСРАФИЛОВ ХӨСНИМӘРДӘН ШӘЙМӘРДӘН УЛЫ

Исрафилов Хөснимәрдән Шәймәрдән улы – 1922 елда Зәй районының Шыкмай авылында туган, Чаллы комиссариаты аша чакырылган. 1 нче Белорус фронтындагы 33 нче армиянең Кызыл байраклы, Югары Днепр исемендәге 362 нче укчы дивизия составында 936 нчы артиллерия полкындагы орудия расчетында төбәп торучы булып, кече сержант дәрәҗәсендә хезмәт итә. 1945 елның 15 февралендә Герой исеменә тәкъдим ителә, әмма Кызыл Байрак ордены белән генә бүләкләнә.

Х.Исрафиловның тәкъдим ителү кәгазе.



НАГРАДНОЙ ЛИСТ

1. Фамилия, имя отчество ИСРАФИЛОВ ХУСНИМАРДАН ШАЙМАРДАНОВИЧ
2. Звание младший сержант 3. Должность, часть наводчик орудия 4 батареи 936 Артиллерийского полка 362 Стрелковой Верхнеднепровской Краснознаменной дивизии

Представить к присвоению звания "ГЕРОЯ СОВЕТСКОГО СОЮЗА"

4. Год рождения 1922 5. Национальность татарин 5. Партийность беспартийный
7. Участие в гражданской войне, последующих боевых действиях по защите СССР и отечественной войне (где, когда) Отечественная война с 15.8.42г. Калин.фр. с 15.8.42г. по 1.4.43г. Брянск.фр. с 1.4.43г. по 10.9.43г. Белоруск.фр. с 10.9.43г.
8. Имеет ли ранения и контузии в отечественной войне лег.ран.14.1.45г. Белор.фр.
9. С какого времени в Красной Армии с 12.4.42г. 10. Каким РВК призван Челнинским РВК Тат.АССР
11. Чем ранее награжден (за какие отличия) медаль "ЗА Б.З. пр.936 АП 362 СКД №07/н от 29.10.43г. орд.КР.ЗВ. пр.362 СВКД №0103/н 19.9.44г.
12. Постоянный домашний адрес представляемого к награждению и адрес его семьи

I. Краткое, конкретное изложение личного боевого подвига или заслуг

При форсировании реки ОДЕР 5.2.45г. орудие, где наводчиком тов. ИСРАФИЛОВ, стояло на прямой наводке.
Огнем орудия уничтожено 4 пулеметных точки и 19 солдат противника
Благодаря тому, что цели были подавлены батальон майора Каверзнева (1208 СП) успешно форсировал реку ОДЕР.
14.2.45г. противник пошел в наступление на д. ВИЗЕНАУ, имея целью отбросить наши части на восточный берег реки ОДЕР.
Орудие тов. ИСРАФИЛОВА стояло на прямой наводке.
Ценою больших потерь, противнику удалось вклиниться в нашу оборону.
Орудие осталось без прикрытия пехоты. тов. ИСРАФИЛОВ был ранен, но с поля боя не ушел и продолжал расстреливать в упор наседавших со всех сторон на орудие солдат противника.
В этом бою орудием тов. ИСРАФИЛОВА уничтожено 4 пулеметных точки, убито и ранено до 150 солдат и офицеров противника, подбито самоходное орудие.
Благодаря героизму тов. ИСРАФИЛОВА, в течении дня отбито 6 яростных атак противника и положение наших войск восстановлено.
Достоин представления к присвоению звания "ГЕРОЯ СОВЕТСКОГО СОЮЗА"

Командир 936 Артполка
гв. Подполковник (САВЧЕНКО)

15 февраля 1945г.

Достоин награждения Орденом Красного Знамени

Командующий артиллерией 362 СВКД
подполковник / ПУГАЧЕВ/

Командир

[illegible] февраля 1945 г.

(Дәвамы киләсе санда).

Михаил ЧЕРЕПАНОВ.

«Миллиард татар» челтәреннән. **Вахит ИМАМОВ** тәрҗемәсе.

График портретта без акыллыгы, инсафлыгы һәм итәгатьлеге йөзенә язылган, шушы яшендә үк һәрчак үз фикере булган, уйчан яшүсмерне күрәбез. Әлеге портретны 1962 елны кадерле әтисе иҗат иткән. Булачак рәссамга биредә әле нибары 14 яшь.



СӘНГАТЬ

Фәйзулла Әминев 1948 елның 16 мартында Ленинград шәһәрендә дөньяга килгән. Аның әтисе – мәшһүр татар рәссамы Фәйзрахман Әминев. Нәселдә рәсем сәнгатенә тартылу көче булганга күрә, Фәйзулла да, әтисе кебек үк, кечкенәдән рәсем ясау белән мавыккан.

Ул әүвәл, 1959-1966 елларда, И.Е.Репин исемендәге сынлы сәнгать, скульптура һәм архитектура институты каршындагы урта мәктәптә белем ала. 1967-1974 елларда шушы ук институтның графика факультетында, совет профессоры, рәссам-график, педагог М.А.Таранов житәкчелегендә укый. Студент чоры Ф.Әминев өчен дә шатлыклы һәм кызык чор буларак истә кала. «Ул чакларда без бергәләшеп үзебез өчен генә дип «нәфис кинофильмнар» төшерергә күнегеп киттек, кинорольләрне дә үзебез үк теләп башкардык. Без бик ачык күңелле, үзара тату студентлар төркеме идек, төрле иҗатны яраттык, театр тамашаларына да бергәләп йөрдек. Мин әле спортның регби төре белән дә мавыктым. Гел рәсемнәр ясап утыручы кеше өчен күпмедер дәрәҗәдә спорт белән дә шөгыль файдага гына дип санадым. Соңрак бу теманы үз иҗатымда бераз яктырттым да, – диде профессор яшьлеген искә алып. – Ә төрле дәрәҗәдәге күргәзмәләрдә исә 1971 елдан, егерме өч яшемнән башлап катнаша башладым...»

1974 елдан алып Фәйзулла Фәйзрахман улы, рәссам-иллюстратор буларак, «Нева», «Аврора», «Костёр», «ХВЗ» («Хочу всё знать») дип аталучы мәртәбәле журналлар белән хезмәттәшлек итә. «Лениздат», «Детская литература» һ.б. нәшриятлары белән дә тыгыз элемтәдә була. Әлеге җаваплы вазыйфаларны башкару өчен мондый эшкә алынучыдан фантазия куәтенә ия булу, өлгерлек таләп ителә, ни дисәң дә, ул чактагы санаулы гына матбугат чараларына игътибар зурдан була ич. Ләкин мондый хезмәтнең бер кимчелекле ягы да бар инде: әлеге иҗат нәтиҗәләрен һәр күргәзмәгә дә куеп булмый. Алар шул басма битләрендә генә туплана бара... Моннан тыш рәссам әдәби китапларны, балалар әдәбиятына кагылышлы әсәрләрне дә бизи һәм балалар, олылар өчен язылган илледән артык китапка йөзләрчә кызыклы иллюстрацияләр иҗат итә!

1974-1975 елларда Ленинградның 8 нче балалар сынлы сәнгать мәктәбендә укытып алгач, 1975-1990 елларда – В.И.Мухина исемендәге Ленинград югары сынлы сәнгать-сәнәгать училищесының рәсем кафедрасында, 1990-1998 елларда инде Санкт-Петербургның Сервис технология институтының «Костюм дизайны» кафедрасында укытучы булып эшли. Студентларга төпле белем бирә. Аннары, 1997 елдан алып Фәйзулла Әминев иләбездәге иң борынгы уку йортларының берсе булып саналучы А.Л.Штиглиц исемендәге Санкт-Петербург дәүләт сынлы сәнгать-сәнәгать академиясенең рәсем кафедрасында доцент булып хезмәт куя башлый. Әлеге академиядә укыту чорында талант иясе профессор дәрәҗәсенә ирешә һәм анда 2020 елга кадәр белем бирә.

Үзгәртеп кору еллары аның өчен дә төрле танышлыклар һәм киңрәк мөмкинлекләр өсти. Һәркем өчен чит дәүләтләргә юллар ачыла. Шунлыктан 1991 елда Фәйзулла Фәйзрахман улына Австрия дәүләтенең Вена каласында «Невский Палас» кунакханәсен бизәү буенча оештырылган бәйгедә җиңеп чыгарга насыйп була. 1992 елда әлеге бина өчен өч йөз акварель һәм майлы буяулар белән унике картина иҗат итә. Аннары АВУ (Австрия) төзелеш фирмасы офисы өчен дә илле акварель рәсем ясый, киндерләргә майлы буяулар белән ун картина яза.

Талант иясе 1997 елда Россия Рәссамнар берлегенә һәм Санкт-Петербург акварелистлары җәмгыятенә кабул ителә. Фәйзулла Әминев 2002 елдан алып «Арт-Эго» иҗат төркемендә. Ул шулай ук Санкт-Петербургның А.Куинджи исемендәге акварелистлар җәмгыяте идарәсе әгъзасы да.

1997 һәм 2001 елларда Санкт-Петербургның «Манеж» күргәзмә залында узган «Мехико-Россия-Акварель» дип аталган акварелистларның халыкара күргәзмәсендә катнаша. Акварель сәнгатенә мөрәҗәгать итүчеләр аның бик катлаулы сәнгать төре булуын яхшы аңлый, әлбәттә. Шуңа күрә бу жанрга омтылучылар, үз сәләтләрен сынап караучылар саны беркайчан да кимеми, мондый иҗатчылар аеруча Санкт-Петербургта елдан-ел күбәя килә һәм алар күргәзмәләр ача, бәйгеләр игълан итә. Мәсәлән, 2005 елда узган акварель буенча халыкара күргәзмәдә бу рәссамыбызның «Раштуа алдыннан төн» хезмәте акварель техникасындагы юеш ысулны кулланып ясаган иң яхшы эш буларак дипломга лаек булды.

Ф.Ф.Әминев 2015 елдан алып А.Л.Штиглиц исемендәге Санкт-Петербург дәүләт сынлы сәнгать-сәнәгать академиясенең рәсем кафедрасы профессоры инде. Ул үз иҗаты өчен дә һәрчак вакыт таба, литография, акварель, майлы буяулы сынлы сәнгатькә өстенлек бирә. Аның иҗатында балет темасына караучы әсәрләр, пейзажлар, натюрмортлар житәрлек. Арадан акварель буяуларның чиста һәм җете тоннарын гына кулланып 2006-2007 елларда ясаган хезмәтләре, әйтик «Василий утравы стрелкасы», «Төн. Җәй» кебек рәсемнәре бер карашта ук тамашачыларның хәтеренә уелып калырлык. Рәс-

ТАРИХЫНДА ИСЕМЛЕ

кордебалет биючеләре үзләре дә бер-берсеннән аерылып тормаслык итеп грим яга бит әле... Рәссам үз игътибарын линия һәм форма уенына, биюдәге очышларга юнәлтә. Останың «Петербург балеты» сериясен ошатучылар бихисап!

Студент чаклардан бирле дусты, сынлы сәнгать белгече, профессор Николай Громов әйтүенчә, Фәйзулла Фәйзрахман улының мондый хезмәтләре үз үзенчәлекләре белән ямьле. Рәссам балет биюләреннән тыш башка төр биюләрне дә, мәсәлән, хис-кичерешләрне бию аша тасвирлап бирүгә юнәлдерелгән фламенконы да үтемле итеп тасвирлаган. Николай Николаевич иҗатчы дустын ихлас мактап, болай да дигән: «Дустым үз иҗатының сәнгати телен еллар уза барган саен үзгәреп торды. Аның кайбер эшләре шулкадәр гаҗәеп матурлыкта, хәтта аларга карап, сокланып туймаслык! Чөнки кайбер рәсемнәренең ясалышы, алардагы төсләр балкышы эмаль ысуллы әсәрләрне үк хәтерләтә!»

Фәйзулла әфәнденең юмор һәм сатира белән дус булып, күңелләрне күтәрә торган шаян сам татар әкиятләрен, бәетләрен дә тасфирлый, аның «Татар әкияте» хезмәтендә Сак-Сок бәете барланган. Арада Шүрәле образын ачыклауга багышланган эшләре дә бар. Фәйзулла Әминевның Габдулла Тукай әсәренә багышланган хезмәте 2011 елда «Хәзинә»дә ачылган «Тукайга 125 иллюстрация» күмәк күргәзмәсенә дә куелды. Бу мәдәни чара алдыннан бар рәссамнарга да шагыйрьнең 125 әсәре тәкъдим ителгән иде, Фәйзулла әфәнде арадан театрга багышланганын сайлаган булып чыкты.

Бүгенге Германиядә мәшһүр өч картина галереясын пинакотека дип атап йөртәләр. Аларда урта гасыр рәссамнарының картиналары да, заманча картина һәм фотосурәтләр дә саклана. Менә Ф.Ф.Әминевның әсәрләре дә Дюссельдорфның пинакотекасы фондында бар. Калган эшләре дә – Санкт-Петербургның XX-XXI гасыр сәнгате музеенда, Санкт-Петербургның дәүләт театр һәм музыка сәнгате музеенда, Германия, Франция, Финляндия һ.б. дәүләтләрдәге шәхси тупланмаларда. «Минем әсәрләрем, өч студентым һәм тагы ике рәссам эшләре белән берлектә Санкт-Петербургта XX-XXI гасыр сәнгате музее нигезен дә тәшкил итте», – дип тә ачыклады Фәйзулла Фәйзрахман улы әңгәмә барышында.

Рәссамның шәхси күргәзмәләре 1990-1996 елларда Германиянең Дюссельдорф, Кёльн, Дормаген, Виттенда уза. 1996 елдагы күргәзмә Германиянең Эмсдеттен каласындагы «Версачо» салонында оештырыла. Калган күргәзмәләрен исә ул төрле елларда Санкт-Петербургның «гигант холл»ында, «Эго» галереясында һәм «Маринский» арт-салонында ача. Ә менә 2013 елда аның күргәзмәсе белән «Эрмитаж-Казан» үзәге тамашачылары да танышты һәм ул XXVI нчы Р.Нуриев исемендәге классик балет буенча Халыкара фестивальгә багышланган иде. Анда останың каләм, монотипия, линогравюра техникасында башкарылган, акварель, пастель белән ясалган кырыктан артык әсәрләре урын алды.

Мәгълүм, балет сәнгате рәссамнарны гасырлар буе үзенә җәлеп итә килүче сәнгать төре. Әлеге татар рәссамы да А.Я.Ваганова исемендәге Рус балеты академиясе белән берничә дистә ел дуслыкта. Бу уку йорты – планетадагы иң яхшы уку йортларының берсе булып санала. Аны тупсасы аша атлап керүчеләр нинди «чәчәкле каторга»га риза булуларын бик яхшы аңлый, ләкин шуңа да карамастан мондый биюләргә төшенергә теләүче тырышлар саны кимегәне юк әле. Һәм аларны сурәтләргә теләүче иҗатчылар саны да елдан-ел арта гына. Фәйзулла Әминевның эшләрендә балет биючеләренең авыр хезмәтен реалистик юнәлеш буенча ачыклау беренчел максат түгел, аларда гомуми һәм күпләрнең исендә калырлык бию позалары, катлаулы хәрәкәтләр геометриясе, сәхнәләрдәге төрле мизгелләр чагылыш тапкан. Мондый әсәрләр Әминевның яңа шәхси күргәзмәләрендә тамашачылар хозурына тәкъдим ителә барган, әйтик, 2018 елда Санкт-Петербург дәүләт театр һәм музыка сәнгате музеенда ачылган күргәзмәсе кысаларында да тамашачылар рәссамның Академиянең балет классларында ясалган, Санкт-Петербург театрларында баручы классик балет спектакльләреннән алган кичерешләре аша барланган графикасы, картиналары белән танышкан. Үз акварельләрендә, эстампларында яисә жанрлы рәсемнәрендә бу иҗатчы балет биючеләренең йөз-кыяфәтләрен тәгаен итеп тасфирламый да. Өстәвенә, биючеләр, әйтик,



рәсемнәр ясавы хакында да әйтмичә калып булмый. Аның мондый рәсемнәрендә балалар да, олылар да бик үз итерлек ихласлык һәм игелеклелек ярылып ята.

Әминевлар династиясе безнең яшәешебезне үз иҗатлары белән шатландыруын дәвам итә. Фәйзулла Фәйзрахмановичның улы Камил дә рәссам һөнәрен сайлаган. «Камил улым 1985 елда туды. 2008 елда А.Л.Штиглиц исемендәге сынлы сәнгать-сәнәгать академиясен уңышлы тәмамлады. Ул – коммуникатив дизайн белгече. Нәшриятларда эшләп, постерлар, каталоглар һ.б. ясады. Ә хәзерге көндә «Мельница» анимацион кино студиясендә хезмәт куя. Улым Санкт-Петербург рәссамнары берлегендә, төрле күргәзмәләрдә катнаша. Камилнең дә иҗат юлы буенча китүе белән канәгатьмен. Минем инде оныкларым да үсеп килә... Җәл, әтиебезнең гомере генә бик озын булмады. Аннан калган остаханәдә дә аның иҗат эшләрен кадерләп саклыйбыз. Әтиебез бар иҗаты аша Габдулла Тукай әсәрләрен бик зурлады, үзебезнең милли мирасыбызга битараф булмады, халык хәтерендә уелып калырлык гаҗәеп матур әсәрләр иҗат итте! Әтиебезнең татар халкының иң талантлы улларының берсе булуын белән ихлас горурланабыз!» – дип йомгаклады әңгәмәне профессор.

Зилә НИГЪМӘТУЛЛИНА.

Мәдәни җомга
8 декабрь
№48, 2023

ГЕНЕРАЛ

Узган елның май аенда Россиянең берничә өлкәсеннән тупланган төбәк тарихчылары Беларусь республикасына сәяхәткә барды. Кабат Татарстанга әйләнеп кайткан чакта, ике сәгатькә генә булса да, Вязьма каласында да туктадык. Каланың үзәк мәйданында генерал Михаил Ефремов хөрмәтенә куелган искиткеч гүзәл һәм гыйбрәтле һәйкәлне күреп шаккаттык. Матурлыгы, аңа Вязьмадагы бар халыкның бүген дә изгеләргә санап табынуы, искиткеч хөрмәт итүе бер гаҗәпләндерсә, иң сәере – армиясын немецлар тар-мар итеп бетергән, шулар чолганышында калгач, инде әсирлеккә эләгеп барган соңгы минутта үз-үзен атып үтергән генералга барча Советлар Союзы территориясендә иң беренче булып куелган шаккаткыч тарихлы һәйкәл бит ул! Аның сугышчан юлы, язмышы да гыйбрәт.

● Брянск-Вязьма казанында немецлар кулына эләккән 650 мең совет әсире Вязьма каласы янында төзелгән лагерьга озатылуны көтеп утыра. 2 ноябрь, 1941 ел.

«Барбаросса» планы буенча дүрт-биш ай эчендә Мәскәүне кулына эләктерү турында хыялланган Гитлер генералларының нияте сугышның беренче дәверендә тулысынча диярлек тормышка ашып бара. 1941 елның 22 июненнән башлап өч көн дәвамында гына да гитлерчылар 250 чакрым ара узып, Минск каласын үз кулына эләктерә. Шушы Гродно-Минск калалары тирәсендә хасил булган казанда гына да 300 меңгә якын совет сугышчысы әсирлеккә эләгә. Ә моннан тыш, Витебск-Могилёв-Гомель юнәлешендә – 580 мең, Киев-Умань казанында – 768 мең, Чернигов белән Мариуполь янында янәдән дә 250 мең әсирләргә төшә. Гитлерчыларның басымы һич тукталмый, сентябрь-октябрь айларында инде алар Брянск-Вязьма калаларына да килеп җитә һәм алар янындагы казанда тагын 663 мең совет сугышчысын әсирлеккә ала. 1941 ел ахырына әсирләрнең саны өч миллион да 800 меңгә җитә. Шуңа өстәп, 1941 елгы канкойгыч бәрелешләрдә генә дә бер миллионга якын совет солдаты һәлак була. Ягъни, 1941 елның 22 июненә 5,2 миллион тәшкил иткән сугышчының фәкать 400 меңгә якыны яки 8 проценты гына исән кала. Совет гаскәре асылда гел чигенергә мәҗбүр була, ә гитлерчылар үзләренең «Үзәк» армия группасын һаман көчәйтә бара. Моны Гитлер генералларының сугышка маһирлык яки полководецлык сәләтенә генә кайтарып калдырырга ярамый, Ватан сугышының беренче айларында совет җитәкчелеге дә зур хаталар ясый. Беренче чиратта, 1930 еллар ахырында Сталин-Ежов җәлладлары совет командирлары арасында үткәргән «олы террор» һәлакәте кискен аяк чала. Хәтта, саннарын искә алу да котычкыч: 1940 елга кадәр Кызыл Армия составындагы коры җир гаскәрләре – 49 меңгә якын, хәрби-һава көчләре – 5600 дән, хәрби-диңгез флоты 3 меңнән артык офицерны югалта.

Сталин аны «туганыдай якын аркадаш» дип санаса да, Гитлерның котелмәгән рәвештә сугыш башлавы бөтен Кызыл Армияне һәм совет дәүләтен тораташ хәлендә калдыра. Беренче ике көндә үк, кубесенчә аэродром чирәмнәрендә килеш, 2500 самолет юк ителә. Гитлер үзе әзерләгән дивизияләрне совет чигеннән 800 метр арага туплап куйган булса, совет ягындагы хәрби частьлар хәтта 800 чакрым кадәр ераклыкта «ята» һәм, әлбәттә, мондый хәлдә бердәм каршы тору, контрһөҗүм оештыру турында сүз дә була алмый. Җитмәсә, немец гаскәрләре оештырган казаннарда, яки алардан чыгышлый, солдатлар белән бергә, 150 меңгә якын офицер, шул исәптән 40 ка якын генерал да әсирлеккә төшә. Алар арасында шактый күренекле генерал-полковник М.И.Потапов, генерал-лейтенантлардан Д.М.Карбышев, М.Ф.Лукин, И.Н.Музыченко, В.Я.Качалов, А.В.Власов, генерал-майор П.Г.Понеделин, С.Д.Данилов, Н.К.Кириллов һ.б. булуын яхшы хәтерлибез. Ләкин генералларны фашистлар гына түгел, ә Берия һәм Сталин җәлладлары да кызганып тормый шул. Тиешенчә оборона оештыра белмәүдә генә түгел, хәтта Германия файдасына шпионлыкта гаепләп, илдә танылган армия генералы, Көнбатыш хәрби округ башлыгы, Советлар Союзы Герое Д.П.Павлов, Балтыйк буе аерым хәрби округ башлыгы генерал-полковник А.Д.Локтионов, генерал-лейтенантлардан И.И.Проскуров, Е.С.Птухин, П.И.Пумпур, П.В.Рычагов, И.В.Селиванов, Герой Я.В.Смушкевич, Н.И.Трубецкой, генерал-майорлардан С.И.Оборин, Г.К.Савченко, Герой Г.М.Штерн, татар егете М.Б.Салихов һ.б. – барлыгы 30 дан артык генерал атып үтерелә.

Мондый коточкыч башбаштаклык урнашкан, үзәк командование дилбегәне тулысынча кулдан ычкындырган вакытта совет сугышчылары арасында да күрелмәгән тәшвиш башлана. Бер 323 нче укчы дивизия сугышчылары гына да 1941 елның 29 июненнән 1 июленә кадәрге арада – 697 дезертир эләктерә, аларның 101 е атып үтерелә. 6 нчы укчы корпус 5000 дезертирны эләктерә һәм окопларга кире кайтара, аларның да бер йөзе, башкаларга сабак булсын өчен, атып үтерелә. Тәшвиш дәһшәте шулкадәр киң булып җәелә ки, хәтта бер хәрби корпус камалышта калгач, андагы 697 коммунист үзләренең партия билетларын юкка чыгара.

Аннары ашыгыч рәвештә мобилизация игълан итү, уңга-сулга карап тормыйча яңа дивизия яки ополчениеләр туплау да гел файдага булмый. Әйтик, 1941 елның август-сентябрь айларында Орел каласында ашыгыч рәвештә яңа дивизия туплыйлар, ә махсус бүлек җентекләп тикшерә башлагач, җыелган сугышчылар арасыннан 35 кешенең элек Антонов бандасында йөргән булуы, 51 енең элек төрмәдә утыруы, 24 енең – кулак булуы, 38 енең Украинаның 1940 елда гына кушылган көнбатыш районнарыннан яки Балтыйк буеннан мәҗбүри рәвештә күчереп утыртылган икәнлеге, 335 кешенең ялган документлар буенча чирле саналуы ачыклана. Алар белән, әлбәттә инде, кәнфитләнеп тормыйлар, сугыш чоры кануннары Бактың исә, мең чакрымнарга сузылган фронт сызыгының икенче бер ноктасы булган Көньяк-Көнбатыш фронтының 15 нче укчы корпусында 71 йөк машинасы һәм 52 трактор ягулык таба алмау сәбәпле хәрәкәтләнә алмый. Шундагы ук 22 нче механикалаштырылган корпустагы 119 танкның 58 ен үзебезнең үк сугышчылар юл булмау сәбәпле шартлатып юк итә. 41 нче танк дивизиясендә дә 12 танкны совет экипажлары үзләре шартлатырга мәҗбүр була. Хәтта Запас фронт башлыгы булып билгеләнгән армия генералы Г.Жуков та октябрь аенда Ставкага сугыш кырларында – 322, ә ремонт базаларында янә 264 танкның запас частьлар булмау сәбәпле хәрәкәтсез ятуы турында рапорт юллый.

Бөек Ватан сугышы тәмамланганнан соң китапларда: «Немец-фашист юлбасарлары ларындагы барча күпер юкка чыгарыла. Авылларның кайберләрен, шул исәптән Петрищевоны составында Зоя Космодемьянская да булган диверсион төркем юк итәргә исәпли.

Шөбһәгә төшмәслек түгел, немец гаскәрләре бер ыргылыш ясарлык ара калдырып, Мәскәүгә якыная. Совет Генштабы ул арада инде җитди әзерлек чаралары күрергә ашыга. Сентябрь аенда Көнбатыш фронт хасил була, аңа җитәкче итеп генерал-полковник Иван Коневны билгелиләр. Конев дошманның төп һөҗүм угы кай тарафка юнәлүен аңлый алмый кала. Ә Гитлерның «Үзәк» армияләр группасы тиз арада хәрәкәтләнеп Вязьма, Ржев, Можайск калаларын уялый, аерым полклар хәтта Тверь (ул вакытта Калинин) каласының бистәләренә дә үтеп керә. Резервтагы 2 нче армияне урталайга өзеп, немецларның танклар колоннасы буенча 516 кеше юк ителә.

Сугышның беренче айларында Кызыл Армиянең сугыш кирәк-яракларына коточкыч мохтаҗлык кичерүен дә онытмаска кирәк. Гаҗәп түгелмени – бер Киев хәрби округы һәм андагы 5 нче, 6 нчы, 12 нче, 26 нчы армияләрне тәэмин итү өчен генә дә 1500 вагон боеприпас җитми. Шул ук вакытта, 1941 елның ноябрь аенда безнең авиация Базалеевка, Василенково, Юрченково станцияләренә тупланган 317 нче механикалаштырылган тау полкын һәм 47 нче укчы тау дивизиясен бомбаларга тотып юк итә. сугыш барышында советлар илендә 1710 шәһәр һәм бистәне, алардан тыш, тагын 70 меңгә якын авылны (28 меңе – Украинада) юк итте», – дип күрсәтеләр («Народное хозяйство СССР в Великой Отечественной войне 1941-1945 гг.» М., 1990). Шул ук вакытта, башка сәер якны да һич онытып булмый, аңа «сөекле» Сталиныбыз үзе нигез салган. 1941 елның 17 ноябренда нәкъ менә ул имза куеп, 0428 номерлы фәрман игълан итә. Ә аның нигезендә Мәскәүгә алып килә торган юлларда бер-ике атна эчендә йөзәрләгән авыл, Можайск һәм Минск юл Мәскәүгә юнәлә. Менә шушы хурлыкка юл куйган өчен такыр башка тимер тарак табарга кирәк бит, Ставка Коневны дошман өчен Мәскәүгә юл ачуда гаепли. Тиз арада Ленинград фронтыннан Г.Жуковны чакыртып кайтаралар. Генерал Конев Көнбатыш фронт белән идарә итүдән читләштерелә, хәзер аны Жуковка тапшыралар.

Бер уйласаң, ул көннәрдә Коневны да элек Көнбатыш хәрби округны җитәкләгән армия генералы Дмитрий Павлов язмышы көтеп тора. Бу очракта Коневны Халхин-Голда Жуков тирәсендә сугышып йөрүе генә коткарып

● Армия генералы Дмитрий Григорьевич Павлов. 1941 елның 22 июлендә атып үтерелә.

● Ике тапкыр Советлар Союзы Герое, маршал Конев Иван Степанович.

ЕФРЕМОВ ФАҖИГАСЫ

УКАЗ
ПРЕЗИДИУМА ВЕРХОВНОГО СОВЕТА СССР
О присвоении звания Героя Советского Союза т.т. ГУРЬЯНОВУ М. А., КОСМОДЕМЬЯНСКОЙ З. А., КУЗИНУ И. Н., особо отличившимся в партизанской борьбе в тылу против немецких захватчиков

●1942 елның 16 февраленда Зоя Космодемьянскаяга Герой исемен бирү турында Указ.

ПРОЛЕТАРИИ ВСЕХ СТРАН, СОЕДИНЯЙТЕСЬ!
КОМСОМОЛЬСКАЯ ПРАВДА
Орган Центрального и Московского комитетов ВЛКСМ
Наше дело правое,— победа будет за нами!
И. СТАЛИН.
Суббота, 13 декабря 1941 г.
КРАХ ВТОРОГО НАСТУПЛЕНИЯ ФАШИСТОВ НА МОСКВУ
В ПОСЛЕДНИЙ ЧАС
ПРОВАЛ НЕМЕЦКОГО ПЛАНА ОКРУЖЕНИЯ И ВЗЯТИЯ МОСКВЫ
ПОРАЖЕНИЕ НЕМЕЦКИХ ВОЙСК НА ПОДСТУПАХ МОСКВЫ

● «Комсомольская правда» газетасы Мәскәү янында Гитлер планнарының җимерелүе турында хәбәр итә. Җиңүче генераллар арасына хәтта Власов рәсеме дә куелган (соңыннан тәре сугып сызылган). Ә Ефремов монда да эләкмәгән.

кала сыман. Өстәвенә, нәкъ шул көннәрдә Ставка Мәскәүне Тверь ягыннан саклау өчен Калинин фронтын да төзеп куя, әлләни эзләнеп тормыйча, анысын һаман да шул «рәнҗетелгән», әмма чыныгу алган Конев кулына тапшыралар. Әлбәттә, Конев тиз арада Калинин-Тверь тирәсендәге бозжраны ныгытуга ирешә, бераздан ул Мәскәү янындагы яуда, ә иң соңыннан Берлин каласын штурмлау барышында таныла. Әмма алардан да бигрәк, маршал Конев сугыш гариплəрен яклап чыгучы бердәнбер гадел, куркусыз һәм туры сүзле полководец буларак дан ала.

Коммунистлар партиясе чәчәк аткан 1960 елларда менә мондый коточкыч хакыйкатьне ачып сал әле: «Фронтовикларның 155 меңе – бер күзен югалткан, 54 меңе дөм-сукыр калган. 28648 ир-ат җенес әгъзасын, 3 миллион да 147 мең солдат бер кулын өздергән, ә 1 миллион 10 мең кеше гомумән кулларсыз калган. Сыңар аягын югалтканнар – 3 миллион да 255 мең. Ике аяксыз да калганнар – 1 миллион 121 мең. Ә кулсыз да, аякларсыз да калган «самавырлар» – 85942».

Сугыштан соңгы елларда шушы гарип-горәбә тимерьюл һәм автомобиль вокзалларында, елгалардагы пристаньнарда хәер сорашкан, тапкан акчасын хәмергә әйләндергән. 1949 елда Сталинның 70 яшьлек юбилеена әзерлек башлангач, аларның һәммәсен дә вагоннарга һәм катерларга төяп, Валаам күле буендагы инвалид йортларына илтеп ташлаганнар...

Янә Мәскәү янына әйләнеп кайтсак, Америка генералы Дуглас Макартур күрәзәчеләрдәй алдан күреп, бик тә дөрес әйткән: «Россиядәге халык, нәкъ Кытайдагы шикелле үк, санап бетергесез. Җирләре күп, чигенергә дә урыннары хәттин ашкан. Аларны яшендәй тизлек белән җиңүгә ирешү мөмкин түгел. Иртәме-соңмы, немецларның һөҗүме җиңелү белән тәмамланачак». Нәкъ шулай килеп чыга да.

5 декабрь көнне Кызыл Армия Мәскәү янында немец гаскәрен тар-мар итүгә ирешә. Бу илкүләм җиңүдә Ерак Көнчыгыштан китереп җиткерелгән Себер дивизияләре генә түгел, фронт башлыгы Г.Жуков кул астында яуга кергән генерал-лейтенант А.Власов җитәкләгән 20 нче, генерал-лейтенант М.Ефремов кул астындагы 33 нче, генерал-лейтенант К.Рокоссовский командалыгындагы 16 нчы армия сугышчылары да хәлиткеч роль уйный. Яраланган генералларга Ленин яки Кызыл Байрак орденнарын тапшыру өчен 29 декабрь көнне Сталин шәхсән үзе госпитальгә килә. Әлбәттә, юлбашчыны фронт башлыгы булган Жуков та озатып йөри. Менә шул вакытта Сталин әллә үзе дә абайлап бетермичә, әллә махсус рәвештә мондыйрак бер җөмлә ычкындыра: «Сез – иртәгә үк фронт башлыгы итеп куярга әзер генераллар!»

Ә Яңа ел бәйрәме узып китүгә, 5 гыйнвар көнне, Сталин Ставка тарафыннан Мәскәүгә чакырылган генералларны бергә җыеп ала. Кемдер анда Кутузовлык чирен кузгатырга ярдәм иткән бугай, максаты аермачык яңгырый: «Без Гитлер фашистларын язгы чәчү җиткәнче советлар иленнән куып чыгарырга, ә моның өчен һәр фронтта барча гаскәр якын арада һөҗүмгә күчәргә тиеш!»

Бу максат өчен, беренче чиратта, Мәскәү тирәсен тиз арада дошман гаскәрләреннән чистартырга кирәк. Ә Мәскәүдән кул сузымындагы Ржев, Вязьма, Гжатск, Руза, Можайск калаларын Гитлерның «Үзәк» армиялар төркеме үз кулында тота. «Үзәк» төркемен немецларның 3 нче һәм 4 нче танк армиялары һәм 4 белән 9 нчы кыр армиялары тәшкил итә. Вермахт гаскәрендә 625 мең сугышчы, 11 мең туп, 354 танк исәпләнә. Совет Ставкасы Ржев-Вязьма юнәлешендәге һөҗүм операциясен, асылда, бик грандиоз һәм хәлиткеч санап планлаштыра. Совет гаскәрләре Ржев-Вязьма-Юхнов-Гжатск калалары юнәлешендә һөҗүм итеп, дошманның «Үзәк» армиялар төркемен кисәкләргә бүлгәләргә һәм аерым-аерым көе юк итәргә тиеш була. Әгәр мондый хыял чынга ашса, әлеге җиңү янында Сталинград та күләгәдә генә калган булыр иде. Совет Генштабынең үзенә күрә бик тә төпле, «яшендәй» җитез планын тормышка ашыру, беренче чиратта, Г.Жуков җитәкләгән Көнбатыш һәм генерал-полковник И.Конев кул астындагы Калинин фронтларына тапшырыла.

(Дәвамы киләсе санда).

Вахит ИМАМОВ.

Мәдәни җомга
8 декабрь
№48, 2023

Сугышка кадәр үк ике

● Сергей Грицевец.



● Григорий Кравченко.

● Яков Смушкевич.

1941 елның 22 июненә кадәр СССРда нибары биш кешегә ике тапкыр Советлар Союзы Герое исеме бирелгән. Сугыш елларында андыйлар саны артачак, әлбәттә, ә А.Покрышкин, И.Кожедуб һәм Г.Жуков хәтта өч тапкыр Герой булачак. Бөек Ватан сугышына кадәр үк каһарман буларак танылучыларның дүртесе – очучы, берсе – котыпчы. Аларның икесе – Папанин белән Денисов кына картайганчы яшәгән, өчесе исә яшьли китеп тә барган. Беренче булып Сергей Грицевец бакыйлыкка күчкән.

Сергей ГРИЦЕВЕЦ

Сергей Грицевец – ул чордагы иң шәп очучы. Ул үзенең Алтын Йолдызларын Испания һәм Халхин-Гол күгендә сугышып ала. Испаниягә командировкага өлкән лейтенант булып китеп, майор булып кайта. Ә Япониядә командиры Забалуевның дошман территориясенә төшеп утырырга мәҗбүр булуын күргәч, үзе дә аның янәшәсенә төшә һәм җитәкчесен японнарның борын төбеннән алып китә. Нибары 30 яшьлек Грицевец 1939 елның сентябрендә Минск аэродромында гадәттән тыш хәл вакытында һәлак була.

Григорий КРАВЧЕНКО

Григорий Кравченко исә Кытайда японнарга каршы сугыша, аңа да өлкән лейтенанттан соң шундук майор дәрәҗәсе бирелә. Аннары Халхин-Голда, полк командиры булса да, үзе дә очудан туктамый һәм Монголия күгендә японнарның 10 самолетын бәреп төшерә. Аннан соң фин сугышында катнаша. Бөек Ватан сугышында 11 нче катнаш авиадивизия командиры була, үзе дә һаман оча. 1943 елның 23 февралендә генерал-лейтенант Кравченконың Ла-5 очкычын атып төшерәләр, сикерергә туры килә, тик парашюты ачылмый. Аңа да нибары 30 яшь була.

Яков СМУШКЕВИЧ

Яков Смушкевич, яки «Генерал Дуглас» – тагын бер чын каһарман һәм шул ук вакытта «халык дошманы» да. Испаниядә командировкада вакытта арысландай сугыша, бригада командирыннан шундук корпус командиры итеп куела, беренче Герой исемен ала. Икенче тапкыр Советлар Союзы Герое исеме аңа Халхин-Голда сугышкан өчен бирелә. Испания белән Монголиягә барулары арасында исә ул яңа техника сыный, Р-10 самолетын Беренче май парадына әзерләгәндә ике аягын берьюлы сындыра. 1941 елның 8 июнендә каһарманны хастаханәдә кулга алалар. Смушкевич гади очучы буларак кына да совет хәрби-һава көчләренә күп файда китерә алыр иде, ә ул бит әле нәкъ менә хәрби операцияләрне оста оештыручы да була. Әмма тәҗрибәле офицерны, Ватанны якларга җибәрү урынына, Бериянең шәхси фәрманы буенча 1941 елның 28 октябрендә атып үтерәләр.

Иван ПАПАНИН

Иван Папанин 1934-1935 елларда Челюскин борынында поляр станция башлыгы була. Дөньяда беренче «Төньяк полюс» станциясен җитәкләүче И.Папанин һәм экспедициянең башка әгъзалары 1937 елның 6 июненнән башлап 9 ай буе бозда Котыптан Гренландиягә кадәр йөзә һәм диссертация якламыйча гына география фәннәре докторы исемен ала, аларга Советлар Союзы Герое исеме бирелә. «Главсевморпуть» башлыгы булып эшләгәндә «Георгий Седов» бозваткычын һәм командасын коткарган өчен Папанин икенче тапкыр Герой исеменә лаек була. Тугыз тапкыр Ленин ордены белән бүләкләнә. Фәннәр академиясендә Океанология институты директоры урынбасары, 1969 елдан 1986 елга – 91 яшендә вафатына кадәр Космик тикшеренүләр хезмәте башлыгы була.

Сергей ДЕНИСОВ

Һәм ниһаять, Сергей Денисов. Ул да Испаниядә сугыша, һәм үзенең беренче Алтын Йолдызын бригада командиры Денисов нәкъ шундагы батырлыклары өчен ала. Халхин-Голда да катнаша, әмма икенче тапкыр Герой исеме аңа фин сугышында «Маннергейм сызыгын өзгәндә оста җитәкчелек иткән өчен» бирелә, ул чакта ул 7 нче армия командующие була. Аннары 30 яшьлек Денисовны

тапкыр Геройлар

● Иван Папанин.

● Сергей Денисов.

Кавказ аръягы хәрби-һава көчләре башлыгы итеп куялар. 1941 елның 20 июнендә исә «частьларның начар хәрби әзерлеге өчен» эшеннән алалар. Августта Качинск авиамәктәбе җитәкчесе итеп күчерәләр, абруе булмау һәм эчкечелеге аркасында аннан да куалар. 1943 елның февралендә, кадрлар җитешмәгәнгә, авиадивизия командиры итеп билгеләләр. Әмма бер елдан соң ук даими эчкечелеге өчен партиядән шелтә белдерелә һәм эшеннән куыла. Тыныч вакытта да салуыннан туктамаганга, 1947 елда отставкага чыгаралар. Шулай да авиация генерал-лейтенанты Денисов, оста очучы булганга, 1971 елда Мәскәүдә Новодевичье зиратында җирләнә.

Валерий ГРАЧИКОВ, «Дзен.ру».
Алсу **ЗӘЙДУЛЛИНА** тәрҗемәсе.

Айга кырын карама

Халык медицинасы чаралары белән дәвалануга керешкәнче, табиб белән киңәшү зарур!

9 декабрь (шимбә). ***Җөмәдел әүвәл аеның 26 нчы көне. 26 нчы Ай тәүлеге. Ай Чаян йолдызлыгында, 4.17 сәгатьтә калка, 13.56 сәгатьтә бата. 4 нче фаза. Көн озынлыгы 7.11сәгать.***

Һәртөрле вәсвәсәләргә бай көн. Әйләнә-тирә дөньяны кабул итү кискенләшә, тәэсирләнүчәнлек арта, чит кеше йогынтысына бирешүчәнлек көчәя. Килешүләр төзү уңышлы. Нерв системасы, аяк зәгыйфь. Балык, мук җиләге, сөт ризыклары ашау файдалы.

Әфлисун сихәте

Югары температураны төшерү өчен, 3-4 бүлем әфлисунны ярты стакан җылы суда 30 минут төнәтәләр, көненә берничә тапкыр эчәләр. Тамак авыртканда, эренле ангина булганда, әфлисун кабыгын чәйнәргә кирәк. Әфлисун кабыгын чәйнәү ашкайнатуны да тизләтә, аппетитны яхшырта, үт куыгы авыруларыннан саклый. Күрем вакытында эч авыртканда, каты шешенгәндә, әфлисун кабыгыннан чәй пешереп эчү булыша.

10 декабрь (якшәмбе). ***Җөмәдел әүвәл аеның 27 нче көне. 27 нче Ай тәүлеге. Ай Чаян йолдызлыгында, 5.41 сәгатьтә калка, 14.04 сәгатьтә бата. 4 нче фаза. Көн озынлыгы 7.10 сәгать.***

Бу көннәрдә организм хәлсез, шунлыктан күбрәк йоклау файдалы. Нерв системасы, сизү әгъзалары зәгыйфь. Кан һәм лимфа авырулары кискенләшергә мөмкин. Кан басымын контрольдә тоту сорала.

Кан тамырларын чистарту

Ярты литрлы банкага чирек стакан укроп орлыгы, 1 аш кашыгы вакланган валериана тамыры, ярты стакан бал салып болгаталар да, кайнар су белән тутыралар. Банканың капкачын яхшылап ябып, җылы урында тәүлек буе төнәтәләр. Сөзеп, суыткычта саклыйлар. Көненә 3 тапкыр, ашарга 30 минут кала, 1 әр аш кашыгы эчәләр. 2 атнадан соң нәтиҗәсе күренә.

11 декабрь (дүшәмбе). ***Җөмәдел әүвәл аеның 28 нче көне. 28 нче Ай тәүлеге. Ай Укчы йолдызлыгында, 7.09 сәгатьтә калка, 14.08 сәгатьтә бата. 4 нче фаза. Көн озынлыгы 7.07 сәгать.***

Айның иң яхшы көннәреннән берсе. Энергетикасы бик уңай. Көтелмәгән очрашулар берсеннән-берсе кызыклырак булачак. Хисләр тернәкләнә, аралашу теләге уяна. Сизү әгъзалары, аеруча күзләр зәгыйфь. Кан басымын контрольдә тоту зарур. Организмны чистарту, ач тору уңай нәтиҗә бирә.

Лимонлы бал йоклата

Йокысызлыктан интеккәндә, 1 стакан җылы суга ярты лимон согы һәм 2 чәй кашыгы бал салып болгаталар да, йокларга ятар алдыннан эчәләр. Яисә 1 аш кашыгы укроп орлыгын (йә вак туралган яшел укропны) 1,5 стакан кайнар суда 30 минут төнәтәләр дә, көн буена эчеп бетерәләр.

12 декабрь (сишәмбе). ***Җөмәдел әүвәл аеның 29 нчы көне. 29 нчы Ай тәүлеге. Ай Укчы йолдызлыгында, 8.38 сәгатьтә калка, 14.40 сәгатьтә бата. 4 нче фаза. Көн озынлыгы 7.06 сәгать.***

(Дәвамы 18 нче биттә).

Айга кырын карама

Авыр энергетикалы көн. Бернинди вәгъдәләргә дә ышанырга ярамый. Бизләр системасы, кан тамырлары, эчәклек зәгыйфь. Үзеңне үпкәләткән кешеләрне кичерү зарур.

Тавыш карлыкканда

Берничә баш сарымсакны вак кына турап, күмелгәнче бал салалар, 20 минут пешерәләр. Суыталар, аннары тагын пешерәләр. Шулай 3 тапкыр кайнаткач, иләк аша сөзәләр, суыталар. Сәгать саен 1 әр аш кашыгы кабалар. Яисә 1 стакан кайнар суда 1 чәй кашыгы сода, ярты чәй кашыгы диңгез тозы эретәләр, көненә 3-6 тапкыр тамакны шуның белән чайкыйлар.

13 декабрь (чәршәмбе). ***Җөмәдел әүвәл аеның 30 нчы көне. 1нче, 2 нче Ай тәүлекләре. Ай Кәҗәмөгез йолдызлыгында, 10.01 сәгатьтә калка, 15.20 сәгатьтә бата. 2 сәгать 32 минуттан яңа Ай. Көн озынлыгы 7.05 сәгать.***

Яңа туган Ай Җир белән Кояш арасында, үзенең караңгы ягы белән Җиргә караган. Ай идарә итә торган һәрнәрсә – хисләр, кәеф, хәтер, кан басымы зәгыйфь. Кан басымы болай да түбән булган гипотониклар өчен бигрәк тә авыр вакыт. Бу чорда укуда уңышлар, тиз савыгу, югары эшчәнлеккә өметләнергә ярамый. Ашаганда талымлы булу хәерле. Аралашуны чикләү зарур.

14 декабрь (пәнҗешәмбе). ***Җөмәдел ахир аеның 1 нче көне. 3 нче Ай тәүлеге. Ай Кәҗәмөгез йолдызлыгында, 11.06 сәгатьтә калка, 16.24 сәгатьтә бата. 1 нче фаза. Көн озынлыгы 7.04 сәгать.***

Бик актив көн, хәвеф-хәтәр инстинкты, агрессия белән бәйле. Бүген чирләп китү ихтыяр көченең җитәрлек булмавын күрсәтә. Күзне арытмаска кирәк.

Иммунитетны ныгыту

200 әр грамм күрәгә белән инжирне юып, салкын суда 10 минут җебетәләр, аннары, артык суын саркытып, турыйлар, 100 грамм төелгән әстерхан чикләвеге, кабыгы белән бергә туралган лимон, 200 грамм бал кушып болгаталар, суыткычта саклыйлар. Көненә 3 тапкыр, ашаганчы, кефирга кушып (болай гына да ярый) 2 шәр аш кашыгы кабалар.

15 декабрь (җомга). ***Җөмәдел ахир аеның 2 нче көне. 4 нче Ай тәүлеге. Ай Сукояр йолдызлыгында, 11.47 сәгатьтә калка, 17.51 сәгатьтә бата. 1 нче фаза. Көн озынлыгы 7.03 сәгать.***

Авыр энергетикалы көн. Теләсә нинди әлемтә, танышулар, күмәк эш бүген кыен кичерелә. Озаграк йоклау хәерле. Тәмләрәк һәм күбрәк ашау теләге зур булса да, чаманы югалтмаска кирәк. Ач торырга ярамый.

Сыр ясау

1 литр сөт, 1 кг эремчек (авыл сөте һәм эремчеге булса, яхшырак), 100 г атланмай, 2 йомырка, 1 әр чәй кашыгы сода һәм тоз кирәк. Сөтне кайнатып чыгаралар, эремчек салалар, кайнап чыккач ук, уттан алып сөзәләр. Атланмайны эретеп, шуңа эремчек, йомырка, сода, тоз салып, яхшылап болгаталар, 20 минут пешерәләр. Шуннан соң, формага салып, тыгызлап бастырып, салкын урынга куялар. Сыр озаграк торган саен тыгызлана, тәмләнәнә генә бара. 2 көндә әзер була.

Йолалар –

(Ахыры. Башы 47 нче санда).

Инде кеше гомере белән бәйләнмәгән кайбер йолаларга, гадәтләргә тукталып үтәргә кирәк дип санныйбыз. Шуны ассызыкларга кирәк, авыл җирендә шактый эшләрне бер гаилә көче белән генә эшләп бетереп булмый (бигрәк тә анарда эшче куллар аз булса), шуңа күрә дә безнең халык элек-электән ярдәмгә тирә-күршеләрне, туган-тумачаларны чакырган.

Сүзебезне **каз өмәсеннән** башларга кирәк дип санныйбыз. Әлеге йола милләттәшләребез яшәгән күп төрле төбәкләрдә таралган, чөнки каз асрау татарда борынгыдан килә, кайсыбер йортларда аларның саны берничә дистәдән дә артып китә. Билгеле, аларны эшкәртү өчен зур көч куярга туры килә. Каз сую һәр җирдә дә бертөслерәк, әмма һәр төбәкнең, шул исәптән, Чүпрәле якларының да, үзенчәлекләре дә бар.

Әлеге төбәктә дә каз муенын иң осталар гына кисә. Бу эш иртә, әле таң атканчы ук башлана. Хатын-кызлар аларның мамыкларын йолкый башлый. Билгеле, эш барышында уен-көлке, җыр осталары булса, кайчакларда җыр да яңгырый, бер-берсе белән шаярып алу, кызыклы мизгелләрне искә төшерү һ.б. була.

Казларның канатлары, каурыйлары аерым алына. Соңыннан канатларны идән, стенадагы, әйберләрдәге тузанны себерү, пәрәвезләрне алу өчен кулланалар, таныш-ларга, туганнарга бүләк итеп тә бирәләр. Каурыйларның берничәсен бергә бәйләп таба майлар өчен «канат» дип атала торган җайланма ясыйлар. Аларны хәтта базарга да чыгарып саталар иде.

Каз түшкәләре мамык-каурыйлардан чистартылгач, иң оста хатын-кыздан казның үпкә-бавырларын, бүтәкәләрен, эчәкләрен, маен алдырталар. Күп төбәкләрдән аемалы буларак, Чүпрәле якларында эчәкләрне орчык ярдәмендә ярып чистарталар да, тәпиләргә урыйлар. Тәпиләрнең үзләрен дә әйбәтләп юып чистарталар. Пешкәч ул бүтәкә кебек үк затлы ризыклардан санала.

Чүпрәледә күлләр, елгалар юк диярлек. Шуңа күрә дә, хәзер телевизорда күрсәткәнчә, гармуннар уйнатып, түшкәләрне көянтәләргә асып, су буена бару гадәте юк. Билгеле, барлык вак тояклэрне дә кул белән алып бетереп булмый, шуңа да аларны факел кебек чорналган салам яки чыра яндырып өтеп алалар һәм юалар. Хәзер моның өчен газ плитәсеннән файдаланалар. Соңыннан өмәдә катнашучылар мунчада юыналар, аларга сый-хөрмәт куела.

Элек каз өмәсе булган йортта кичен аулак өй (мәзәк) үткәрелә иде. Олылар яшьләргә комачауламас өчен тирә-күршеләргә яки туганнарга киткәч, бирегә кызлар, егетләр җыела. Билгеле, барлык теләгәннәр дә керә алмый, чөнки урын да аз һәм кайберләренең кермәве дә хәерлерәк була. Сирәк кенә булса да күрше авыллардан да кунак кызлары, егетләре булуы мөмкин, гадәттә, алар хуҗаларга туган-тумача туры килә. Өйләрдә стена буена табуреткалар өстенә озын такта куелып сәкеләр эшләнә, шунда яшьләр тезелеп утыра. Бала-чаганың урыны мич башында, алар шуннан уеннарны күзәтә.

Мәзәкнең иң кадерле кешесе гармунчы була иде. Тальян яки хромка гармун тавышы яңгырагач, җыр-биюләр башлана, төрле уеннар оештырыла: йөзек салу, әйлән-бәйлән һ.б. Мәсәлән, «Су агышы» исемле уенны хәзерге вакытта сәхнәдә башкарыла торган рус, татар биюләрендә дә очратабыз. Ләкин, Чүпрәле төбәгендә ул бүтәнчәрәк башкарыла иде. Кулга-кул тотынышкан парлы яшьләр, кулларын күтәрә төшеп, «күперчек» ясыйлар. Хәзерге чордан аермалы буларак, сафларның алгы өлешендә парсыз егет яки кыз баса. Ул гармун тавышына кушылып, бии-бии яки биегән булып алдагы парның сыңарын кулыннан тотып, үзе белән әлеге күперчек астыннан алып, артка үтә. Алда так калган уенчы да сафтан берәү белән шулай ук артка таба уза. Кыюрак егетләр кызларның билләреннән дә кочып чыгарга мөмкин, алар шуңа омтыла да. Бу уен шактый озак дәвам итә, чөнки егетләр, үзләренең күңелләренә хуш килгән кызның биленнән тотып, әлеге «күперчек» астыннан үтүне үзләре өчен зур бәхет итеп саный иде. Бер үк вакытта сафта тезелеп торучы уенчылар да биеп, җырлап алга таба хәрәкәт итәләр.

Чүпрәледә бу кичәне «мәзәк» дип атыйлар, ул әдәби телдә уен-көлкене аңлата торган сүз һәм күпмедер дәрәҗәдә шул мәгънәгә туры килә кебек. Шунысы әһәмиятле: каз өмәсендә катнашучыларга элек исерткеч эчемлекләр куелмый һәм шулай ук кичәгә килүче егетләрдән дә аракы исе килми иде.

Йорт күтәрү өмәсе. Йортларны Чүпрәле якларында элек нарат яки усак агачыннан салырга тырыштылар, хәзер инде кирпечтән дә шактый күп өйләр калкып чыкты. Йорт төзү, шулай ук, зур хезмәт куюны сорый торган эш. Иң элек бура бурала, идән, түшәм такталары әзерләнә, бүрәнәләр чистартыла, эчке ягы ышкылана, һәр бүрәнәгә, шул исәптән тәрәзә араларындагы кисәкләргә дә йортның өске өлешенә күтәрү җиңел түгел, ярдәмгә туган-тумача, дус-иш, тирә-күрше җыела.

Йорт күтәрү дә иртәнге якта башлана, чөнки бу вакытта гадәттә җил булмый диярлек, югыйсә бүрәнә өстендәге мүкне җил очырып бетерер иде. Олы яшьтәге ир-ат, кайчак бу эшкә хатын-кыз да кушыла, тигез катлам итеп бүрәнә өстенә мүк (нүек) яки сүс (пәзи) җәя. Мүкне Чуашстан урманнарыннан махсус җыеп, базарга китереп саталар иде яки йорт төзүчеләр (салучылар) үзләре үк шуннан барып алды. Җил исә башласа, мүкне суга манчып алалар. Яшьләрнең бер өлеше тамгалар буенча бүрәнәләрне әзерләп куя, ә бер өлеше аны өскә күтәрә. Бүрәнәләрне урыннарына урнаштырганда бик сак эш итәргә кирәк, чөнки куелган мүкне бәреп төшерергә ярамый, йә булмаса үзең дә очып төшүең бар. Шуңа да иң таза ир-егетләр бүрәнәне очыннан бау (аркалык) белән күтәреп куя. Матча астына йорт хуҗаларына байлык, иминлек теләп, көмеш акча куеп калдырыла. Халык күп булганда, бер үк вакытта мүкне бүрәнәләр арасына кечкенә көрәкчекләр, калаклар белән тыгызлап тыгу, кагу эше дә башкарылырга мөмкин. Бу эшне кубесенчә картлар башкара иде.

Соңыннан өмәдә катнашучыларга сый-хөрмәт куела. Өстәлне әзерләүдә туган-тумача, тирә-күрше дә катнаша. Хатын-кыз кемдер коймак, кемдер ботка, кемдер бүтән төрле ризык алып килеп йорт хуҗаларына тапшыра, ә алар үз чиратында бу ризыклар белән өмәдә катнашучыларны сыйлый. Элекке заманнарда йорт күтәргәндә исерткеч эчемлек кулланылмый иде диярлек, эчүчеләр булса да берничә генә кеше була иде..

Өйне җылытыр өчен, гадәттә, ике мич ясала. Берсе – зур мич, аны «урыс пиче» дип тә атыйлар. Мондый зур мичләрне махсус осталар гына чыгара, чөнки аның ипи пешерә торган өлешендә гөмбәз булырга тиеш, андый осталар халыкта зур хөрмәткә ия була иде. Мичнең ипи пешерә торган бүлемендә ут каршында коймак, кабартма, бәрәңге пешереп була. Мич янып беткәч кисәүләрне кисәү агачы белән тартып чыгарып, «пумала» белән мич төбендәге көлне себереп алып, махсус эшләнгән агач көрәк белән ипиләрне тезеп чыгаралар да, мич авызын калай капкач белән каплыйлар. Шуның янына калган көмерләрне җыештырып өеп куялар, бу өстәмә җылылык бирә һәм ипи дә яхшы пешә. Ул заманнарда ипи пешерергә камыр әзерләү өчен бар йортта да куәс чиләге (куашна) булмый, шуңа да күршеләрдән алып торырга туры килде. Куашна белән бергә әчетке дә (ацкамыр) да алып торалар, соңыннан, шул ук күләмдә итеп, әчеткене кире кайтаралар.

Кайбер кешеләр кечкенә мич – «галанка» да ясый. Ул бераз ара калдырылып зур мич белән рәттән урнаштырыла. Аңа да плитә көйләп була. Салкынча булганда, галанканы җәй көне дә ягып җибәрәләр. Аның учагы зур мичкә каршы ясала. Утын булмаганда аны салам яки тизәктән ясаган кирпеч белән дә ягалар. Мичләрне елга берничә тапкыр акшарлыйлар.

Янгын белән бәйләнешле тагын бер әйбергә игътибар итәсебез килә. Элек һәр йортның урам ягындагы почмагына чиләк, балта, багор, баскыч рәсемнәре тешерелгән такта кисәкләре кагып куелган була иде. Янгын булган очракта йорт хуҗалары, шушы әйберләрне алып барып, янгын сүндерүдә катнашырга тиеш. Бу да янгын сүндерүчеләрнең даими күзәтчелегендә торды.

Кайсыбер йортларда «галанка» миче белән стена арасына сәке эшләнергә мөмкин. Ул идәннән якынча ярты метр биеклегендә булып, аның өстендә ашый, йоклый, намаз укый, кул эшләрен башкардылар. Сәке астында хуҗалык әйберләре, яшелчәләр сакланырга мөмкин, шунда ук казлар бәбкә чыгара, кечкенә бәбкәләрне дә салкын вакытта шунда ябып торалар. Моннан башка сәндерә дә булырга мөмкин, аны түшәмнән 50-60 см. астарак ясыйлар. Ул да балаларның яраткан урыны, чөнки анда олы яшьтәгеләр менми, балалар үз ирекләрендә, шуңа да күп балалы гаиләләрдә бу урынны алыр өчен еш кына бәхәс була.

Зур мич белән стена арасында бушлык кала. Шунда, кыш көннәрендә, кайсыбер хуҗалыкларда яңа туган бозаулар, бәрәннәр урнаштырыла торган иде. Мич артында ук юыныр өчен дә урын ясала, бирелә комган яки кулъюгычтан файдаландылар.

Һәр йортның тәрәзә төпләрендә гөлләр үстерелеп, татарлар яшәгән барлык төбәкләрдәге кебек, алар игътибар үзәгендә булды. Заманында Воробьев та: «Татарларның иң ярлы йортларында да тәрәзә төпләрендә тамчылы яки яран гөле үсә. Русларда гөлләр бары тик байларда гына булып, калган халыкларда алар революциядән соң гына күренә башлады», – дип язды.

Бәрәңге утырту. Бәрәңге утырту (алма чәчү) шулай ук күп кул көче сорый торган эш. Алдан бакчаны әзерләргә кирәк. Элекке заманнарда бәрәңге (алма) бакчаларын күбесенчә көрәк белән казыйлар (басалар) иде. Соңрак ат сабаннары, аннары тракторлар белән сукалый башладылар.

Бәрәңгене, татарлар яшәгән күпчелек төбәкләрдәге кебек, сука белән утырталар. Хәтеремдә, сугыштан соңгы елларда, атлар җитешмәгәнгә, суканы кешеләр дә җигелеп тартканны.

Иң элек сука белән озынлыгы якынча илле метр (озынрак та булырга мөмкин) буразна сызып үтәләр. Шушы буразнага, араларын 25-30 см. (бу араны «чабата буе» диләр) калдырып, орлык бәрәңгесен салып чыгалар. Бәрәңге салучылар күп булырга тиеш, югыйсә өлгереп булмый һәм бу эш озакка сузыла. Шушы вакытта инде тирә-күршеләр, туганнар ярдәмгә килә. Буразна беткән җир «буразна башы» дип атала. Гадәттә, бирелә олы яшьтәге тәҗрибәле кеше була, сукачы сукасы белән борылып өлгергәнче, ул үзенә бирелгән арага орлыкларны куеп өлгерергә тиеш, юкса эш туктап торырга мөмкин.

Гадәттә, бакчаның зурлыгына карап, 30 дан 50гә кадәр буразна була. Суканың мөгезеннән (балакасыннан) тәҗрибәле кеше

халык мирасы...

Кабер казырга шактый кеше күп җыела, бу хәзерге заманда да шулай. Алар, чакырылып түгел, үз теләкләре белән килә. Кабернең озынлыгы үлчәү таягы белән алына, ә ул үз чиратында мәеттән 20-25 см. озынрак булырга тиеш. Кабер урынын зираттагы эшләрне алып баручы кеше күрсәтә. Гадәттә, туган-тумачаны бер тирәгәрәк күмәләр.

Кабер казый башлаганда, мәчет карты, дога укып, җир йомшак булганда, дүрт почмаклап чирәмне дә кисеп, туң булса балта белән чабып ала. Бүтән төбәкләрдә мәетне ләхеткә салалар. Ләхет дип кабернең көньяк өлешендә уеп ясалган җире атала. Чүпрәледә «шалгама» белән күмәләр: кабер бер метр чамасы тирәнлектә казылгач (сары-кызыл туфракка җиткәч), ике янда киртләч җир калдырып, тагын 70-80 см, ягъни «мәет Мәнкир белән Нәнкир (фәрештәләр) сорау алырга килгәндә торып утырырлык», җир казыла, шуны шалгама дип атыйлар. Киртләчләр мәетне гүргә иңдергәндә басып торыр өчен эшләнелә. Хатын-кыз мәетен күмгәндә киртләч бер якта гына (төньякта) калдырыла, чөнки гүргә иңдерүче ир-ат хатын-кыз мәетенең өстендә аягын аерып басып торырга тиеш түгел.

Шалгама эченә һәр ике якка өчәр имән багана утыртыла, аларга аркылы агачлар (пираклат) куела, шулар өстенә калын нарат такталары җәелә. Шулай эшләгәч кабер беркайчан да ишелми диярлек. Кабер казыганда, берничә балта тота белүче кеше шушы агачларны һәм такталарны эшкәртеп, әзерләп куя. Кабер казылып беткәч, аны сакларга бер кеше калдырыла, калганнары җеназа алырга китәләр.

Шалгаманы казыр өчен «цалыр» дигән махсус җайланма кулланыла. Ул, зур өтерге рәвешле итеп, тимердән эшләнә, кул белән тотар өчен ярымдугага охшаган тоткы беркетелә. Аңа ике тармаклы агач сап куела. Дүрт-биш кеше цалырны күтәреп көч белән җиргә бәрәләр, ә аста берәү тезләнгән килеш тоткадан цалырның очын кирәк урынга юнәлтә барып, җирне каертып ала. Цалыр белән эш итәр өчен, аның остасы булырга кирәк, югыйсә тез капкачын имгәтү очраклары да булгалый.

Кабернең әзер икәнлеге турындагы хәбәрне берәү зираттан кайтып әйткәч, мәетне юалар. Суны махсус коедан дога укып тутыралар, чиләкләрнең өстен томалыйлар һәм коедан кайтканда беркем белән сөйләшмиләр. Чүпрәленең үзендә, мәсәлән, суны Миңналим исемлек карт яшәгән йорттагы коедан алалар иде. Чөнки бу кое сиртмәле, аның өсте һәрвакыт ябык була, суны аннан бер чиләк белән генә алалар, шуңа да ул чиста саклана.

Әгәр мәет ир затыннан булса, аны өч кеше юа. Үлек олы гәүдәле булса, ярдәмгә тагын бер-ике туганнары-якыннары керергә мөмкин. Мәетне махсус «кабык» дигән җайланмага салып юалар, ул бераз авыш була, шуңа да су аяк очына таба агып төшә. Суны махсус «сөннәтле» комганнар белән салып торалар. Мондый комган кулдан эшләнгән була, борын очына алка кидерелә, шуңа да ул «сөннәтле комган» дип атала. Мәетне юучылар өчен махсус кулкигечләр, алъяпмалар тегелә. Хәзер моның өчен резинадан эшләнгән махсус медицина кулкигечләре кулланыла. Мәетне башыннан алып аяк очларына кадәр сабынлап, шул исәптән борын, колак тишекләрен дә юалар. Аннары коендырып тәнен махсус (тән киптергече) чүпрәк белән киптерәләр.

Хатын-кызлар алдан ук кәфен әзерләп (печеп) куя. Кәфен 10-12 м. бүз яки марлядан булырга мөмкин. Мәеткә башта ләхет күлмәге кидерелә, кәфенгә төргәч аны баш, бил, аяк турыларыннан бәйләп куялар. Элек, кәфенгә төргәч, мәетне күрсәтү тыела иде. Хәзер баш ягыннан кәфенне бәйләгәнче мәрхүм белән хушлашырга рөхсәт ителә. Бары тик аңа кагылырга, күз яше тамызырга ярамый. Шулай ук кычкырып елау да тыела. Мәетне юучыларга сәдака бирелә. Озатканда мәетне тагын одеялга яки паласка чорныйлар, өйгә ислемай сиптерәләр. Шуннан соң картлар тәһлилгә керә. Догалар укылгач, әйтелгән тәһлилләрне, шул исәптән төнлә белән карчыклар укыган (тарткан) тәһлилләрне дә, тутырылган корьәне булса, аны да, багышлыйлар. Тәһлилдән соң шунда булган кешеләргә мәетнең туганнары акча, сөлге яки кульяулык, сабын тарата.

Мәетне аягы белән алга таба алып чыгалар һәм җеназага салалар. Җеназа укыла. Элек җеназа укырга картлар гына, хәзер инде шунда катнашучы барлык ир-ат та баса. Җеназа укылганнан соң, мулла вазыйфасын башкаручы: «Җәмәгать, бу кеше яхшы идеме?» – дип сорый. Аңа: «Яхшы иде!» – дип җавап бирәләр. Шуннан соң җеназаны күтәреп зиратка юл алалар. Елның вакытына һәм зиратка кадәр араның ераклыгына карамастан, җеназа кулда һәм кызу алып барыла. Хатын-кыз мәетен алып барганда, җеназа өстенә агач яки тимер чыбыктан дуга куела һәм ул чаршау белән ябыла.

Мәетне гүргә иңдерү өчен кабергә өч кеше, гадәттә икесе туганнарыннан, якыннарыннан, төшә. Аны йөзе белән кыйблага каратып салалар, баш, бил һәм аяк очын бәйләгән бауларны чишәләр. Мәет хатын-кыз булса, аны кабергә күчергәндә һәм шалгаманы такталар белән томалаганчы, кабер өстен чаршау белән каплап торалар. Мәчет картларыннан берәү дога укып җир кисәге бирә, аны мәетнең баш очына куеп калдыралар. Шуннан аркылы агачларны куеп такталарны җәяләр һәм туфракны кабергә төшерә башлыйлар. Берәү такталар урыннарыннан кузгалмасыннар өчен туфрак белән томаланганчы кабердә тора. Элек кызыл (сары) балчык төшерелә. Үлчәү таягы кабергә кадап куеп калдырыла. Туфрак өелеп беткәч, булса, рәшәткә урнаштырыла. Элек кабер өстенә рәшәткә дә, һәйкәл дә куелмый, үлчәү таягы гына куела иде.

Шуннан соң дога укыла. Дога укылып беткәч, зиратта булган барлык кешеләргә сәдака өләшенә. Мәрхүмнең туган-тумачасы күп булганда, сәдаканы ун һәм артыграк кеше өләшергә мөмкин. Сәдаканың күләме һәркемнең матди хәленә карый, бары бер генә шарт бар, ул да булса дога укучыларга күбрәк бирү. Кешеләр таралышкач, кабернең дүрт почмагына дүрт кеше (карт) утырып дога укыйлар. Элек хатын-кызга зиратка керү тыела иде, хәзер моңа бик игътибар итмиләр.

Мәетне алып киткәннән соң, өйне һәм мәет яткан әйберләрне юып, чистартып чыгаралар. Зираттан кайтучылардан берәү, өйгә кереп дога укый.

Мәрхүмне искә алып, күмгәннең өченче, җиденче, кырыгынчы һәм бер ел (елашы) тулган көннәре билгеләп үтелә. Өчесе үтми торып, мәет чыккан өйдә ашарга һәм эчәргә ярамый. Бу көннәрдә йорт хуҗаларын туган-тумачалары, күрше-тирәләре ашка чакыра.

(Дәвамы киләсе санда).

Иршад ГАФАРОВ,
Зәки Нури исемендәге
премия лауреаты.

инде ут бирү вакыты берничә сәгатькә озайтыла.

Шуны да ассызыкларга кирәк, барлык йортларда да туйлар өстәл артында үтмәде. Шуңа да кунаклар идәнгә, аякларын бөкләп, тезелешеп утырды. Билгеле, хәзерге заманда моны күз алдына китерергә дә авыр.

Ул вакытта өстәлләр дә хәзерге кебек мул ризыктан сыгылып тормады. Менә ул заманнардагы якынча меню: бавырсак, кош теле (зәймә), калач, казанда майда пешкән кабартма, клиндер, прәннек, печенье, пирог, балык консервлары, тозлаган балык, май, корт, каймаклы катык, бәрәңге, ит, аш (ләкшә), сирәк очракларда тозлаган кыяр яки кәбестә, винегрет (шулай ук сирәк йортта), кыш көне булса – холодец (койка).

Иң элек табынга чәй бирелә, ул гадәттә күпләп эчелә, шуңа күрә тирә-күршеләрдән берничә самовар алып килеп куялар. Аш иң соңыннан чыгарыла, бу инде мәҗлеснең ахырга якынлашып килү билгесе дә була. Аштан соң, өстенә ит кисәкләре куелып, берничә тәлинкә белән бәрәңге чыгарыла. Һәр кунак үз кашыгы белән шул ризыкны алып ашый, аерым тәлинкә бирелмәде. Шуннан кунакларның бер өлеше таралыша башлый, туган-тумача, якыннар тагын бераз вакытка калып, бәйрәм барышында бер тамчы ризык та капмаган хуҗалар белән чәй эчәләр.

Мәет күмү.

Кеше туа, үсә һәм якты дөньядан китәргә дә мәҗбүр була. Мәетне күмү Чүпрәле якларында да ислам кануннары белән үткәрелә, бу хәтта совет чорында да шулай булды (кайбер искәрмәләрне санамаганда).

Кеше төнлә яки иртәнге якта вафат булган очракта аны шул көнне үк күмәләр, ә инде көннең икенче яртысында булса, күмү икенче көнгә калдырыла. Бары тик читтән кайтасы туганнары булса гына, мәет берничә көн өйдә ятарга мөмкин.

Мәетне такта яки бүтән каты әйбер өстенә салалар, югыйсә ул бөкерәеп катарга мөмкин, ияген, авызы ачылмасын өчен, яулык белән тарттырып бәйлиләр, ә корсак өстенә кайчы куела. Өйдәге көзгеләр, мәет хатын-кыз булганда, тәрәзәләр дә томалана. Төнлә һәм көндез мәет янында кешеләр булырга тиеш, бу «төнәтү» дип атала. Гадәттә, төн утыручы аерым әбиләр була. Алар дини китаплар укый, пәйгамбәрләр тормышында булган гыйбрәтле хәлләр турында сөйли, тәһлил әйтә. Мәет яткан бүлмәне салкын тотарга тырышалар, хәттә аскы якка таз белән кар яки марганцовкалы су куялар.

Мәк тамаша залларына чакыра

Г.КАМАЛ ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ АКАДЕМИЯ ТЕАТРЫ

1 декабрь – «Игезәк» (Р.Зәйдулла). Артист Рамил Вәҗиевнең юбилей кичәсе.
2 декабрь – 14.00 – «Кәҗә, сарык һ.б.» (И.Зәйниев). 18.00 – «Гөргөри кияүләре» (Т.Миңнуллин).
3 декабрь – 12.00 – «Кәҗә, сарык һ.б.» (И.Зәйниев). 17.00 – «Шәрык клубы» комплексында – «Моңлы тарих» дип исемләнгән ретро-концерт. 18.00 – «Рәшә» (Ә.Еники).
6 декабрь – К.В.Иванов исемендәге Чуаш драма театры сәхнәсендә,
7 декабрь – Апас районы мәдәният йортында – «Өйләнәм.tat» (И.Зәйниев).

К.ТИНЧУРИН ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ ДРАМА ҺӘМ КОМЕДИЯ ТЕАТРЫ

1 декабрь – «Мәхәббәт баскычы» (Ш.Фәрхетдинов).
2 декабрь – «Ай, былбылым!» (Ш.Фәрхетдинов).
3 декабрь – «Алай түгел, болай ул» (Т.Миңнуллин).
5 декабрь – «Ай, былбылым!» (Ш.Фәрхетдинов).
6 декабрь – «Ашина» (Р.Зәйдулла).
7 декабрь – Күренекле артистка Исламия Мәхмүтованың 80 еллыгы уңаеннан «Кыр казлары артыннан» дип исемләнгән искә алу концерт-кичәсе.

Г.КАРИЕВ ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ ЯШЬ ТАМАШАЧЫ ТЕАТРЫ

1 декабрь – «Ал җилкәннәр» (А.Грин).
2 декабрь – Туймазы Татар дәүләт драма театрының «Борһан йорты» спектакле.
3 декабрь – 11.00 – «Әлифба» (Л.Әхмәтҗанова, Ф.Насыйбуллин, Э.Яруллина). 18.00 – Әлмәт Татар дәүләт театрының «Дөм» спектакле (Л.Толстой әсәре буенча).
4 декабрь – Әтнә Татар дәүләт драма театрының «Наташаның хыялы» спектакле.
5 декабрь – Ачинск дәүләт драма театрының «Первая любовь» спектакле.
6 декабрь – Сарапул дәүләт драма театрының «Сказка о мертвой царевне» спектакле.
7 декабрь – «Доминанта» камера драма театрының «Тихий свет» спектакле (Р.Козырчиков).

«ӘКИЯТ» ТАТАР ДӘҮЛӘТ КУРЧАК ТЕАТРЫ

1 декабрь – 11.00 – «Страна чудес Алисы» (Л.Кэрролл әсәре буенча). 19.00 – «Дитя Аллаха» (Н.Гумилев).
2 декабрь – 15.00 – «Репка-Ряба-Колобок» (Н.Шмитько инсценировкасы).
17.00 – «Камал комедияләре» (Г.Камал).
3 декабрь – Фойеда – «Один день из жизни улитки» (Ольга һәм Юрий Устюговлар). Зур залда – «Муха-цокотуха» (К.Чуковский). Кече залда – «Кәтүкнең сихри төшләре» (И.Нәфиев, Х.Ибраһим).
5 декабрь – «Ночь перед Рождеством» (Н.Гоголь).
6 декабрь – С.Өметбаев исемендәге Минзәлә Татар дәүләт драма театрының «Шулай булды шул» спектакле (Т.Миңнуллин).
7 декабрь – «Конек-Горбунок» (П.Ершов әсәре, Л.Кожевников инсценировкасы).

Г.ТУКАЙ ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ ФИЛАРМОНИЯСЕНЕҢ КОНЦЕРТ ЗАЛЫ

2 декабрь – «Путь героя» беренче иммерсив психологик моно-спектакль.
3 декабрь – Әдәби-музыкаль лекторийның «Ак җилкәннәр» дип исемләнгән концерт программасы. Татарстанның халык, Россиянең атказанган артисты Георгий Ибушев, Гөлнара Байназарова, Тимур Сабиров, Оксана Шәйдуллина һ. б. катнаша. Программада – татар композиторлары җырлары һәм романслары.
4 декабрь – Алиса Маминаның «Зорька алая» дип исемләнгән концерты.
5 декабрь – Филармония джаз оркестры һәм Валерий Сюткин концерты.
6 декабрь – «Маяковский – Есенин. Дуэль в стихах» дип исемләнгән шигърият кичәсе.
7 декабрь – Валерий Михальченко исемендәге Чиләбе камера хоры концерты.

Шикәр акылны зәгыйфьләтә

Лондон Империя колледжы галимнәре канда шикәр микъдары күп булу хәтта икенче тип диабеттан интекмәүчеләрнең дә акылын зәгыйфьләндерүгә булышуын ачыклаган. Галимнәр ун ел дәвамында 50 яшьтән өлкәнрәк 5189 кешенең сәламәтлеген күзәткән. Аларның когнитив (танып белү – игътибар, сөйләм, интеллект, хәтер) сәләтләрен бәяләгәннәр һәм кандагы шикәрнең озак вакыт эчендәге уртача концентрациясе турында мәгълүмат бирә торган HbA1c гликогемоглобины микъдарын контрольдә тотканнар. Картая барган саен, сынауда катнашучыларның барысының да когнитив сәләтләре кимегән, әмма каннарында гликогемоглобин микъдары югары булганнарның акыл сәләте һәм хәтере тагын да начаррак булган. Икенче тип диабетның Альцгеймер авыруына китерү ихтималы зур икәне тикшерүчеләргә инде мәгълүм булган, әмма нейродегенератив чирләрнең турыдан-туры кандагы шикәр микъдарына бәйле булуы әле беренче тапкыр дәлилләнгән. Икенче тип шикәр чире булганда, тукымаларның инсулинга сизгерлеге кимү нәтиҗәсендә канда глюкоза арту күзәтелә. Ул симерүдән интегүчеләрдә башланырга яки нәселдән килергә мөмкин. Дәвалауның бер ысулы – шикәрсез диярлек диета.

(“Science Alert”).

Җәһәннәмгә әйләнгән җәннәт

